МУЛ УҢЫШ: Отумы, оттырумы?

> 15

ЙОРТ ХАЙВАННАРЫ: Кемгә – юаныч, кемгә – бәла

> 17

ИЛШАТ РӘХИМБАЙ: «Киноның кыйммәтен аңлап җиткермибез»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 155 (28928) | Җомга | 21 октябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

tatarstan.ru

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ: «КЫЕНЛЫКЛАРНЫ БЕРГӘЛӘП ҖИҢӘ БАРАБЫЗ»

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Дәүләт Советына быелгы Юлламасы катлаулы вазгыять шартларында яңгырады. Президент та чыгышын махсус хәрби операциядә һәлак булган каһарманнарны бер минут тынлык белән искә алудан башлады.

Мәртәбәле чарага үз вазыйфаларында 20 елдан артык эшләүче авыл башлыклары, авыл хуҗалыгы тармагына зур өлеш керткән фермерлар, үз һөнәренә тугры укытучылар, гомуми гаилә стажы 100 елдан артып киткән медицина өлкәсе династияләре, спортчы-чемпионнар чакырылу аңа җылылык өстәде һәм Юлламаның мәгънәсен тагын да тирәнәйтте. Рөстәм Миңнеханов аларның һәркайсына аерым игътибар күрсәтте, аларны алкышларга күмделәр. Киләсе 2023 ел исә республикада Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде.

> 2–7

Ишетми калмагыз

Күпбалалы әтиләр (16 яшькә кадәр өч һәм аннан да күбрәк баласы булганнар) өлешчә мобилизациядән азат ителгән. Бүгенгә 9500ләп ир-ат хәрби частьлардан алынган һәм гаиләләренә кире кайтарылган. Бу турыда Россия Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин үзенең телеграм-каналында язган. Аның сүзләренә караганда, өч һәм аннан да күбрәк балалары булган ир-атларны мобилизацияләүдән азат итү турында мөрәҗәгатьләр күп килгән. Ә бу карарны алар Россия Оборона министрлыгы җитәкчелеге белән берлектә кабул иткән.

Дәүләт Думасы Рәисе өлешчә мобилизациягә кемнәрнең эләкмәвен дә искә төшергән. Алар – сәламәтлеге аркасында хәрби хезмәткә яраксыз һәм вакытлыча яраксыз булганнар («Г» һәм «Д» категорияләре), гаиләдә тәрбиягә мохтаҗ яки I группа инвалидны даими караучылар, үзенең энесе яки сеңлесенә опекун яки попечитель булганнар (гаиләдә бу эшне башкара алырлык башка кеше булмаганда), бер яки аннан да күбрәк баласы булган хатын-кызлар, әниләреннән башка бер һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүчеләр.

Татарстанда коронавирус белән авыручыларның саны кими. Әйтик, пәнҗешәмбе әлеге авыру 199 кешедә ачыкланган, шулардан 44 кешене хастаханәгә салганнар. Стопкоронавирус.рф сайты мәгълүматларына караганда, 738 авыру савыккан, үлүчеләр теркәлмәгән.

Пандемия башланганнан бирле республикада рәсми рәвештә COVID-19 авыруының 185848 очрагы расланган. 181742 кеше сәламәтләнгән, барлыгы 2482548 кеше тулы вакцинация узган.

Ел башыннан бирле Татарстанда Үзәк банк тарафыннан 20 «кара» кредитор, ике финанс пирамидасы һәм кыйммәтле кәгазьләр базарының легаль булмаган катнашучысы ачыкланган. Хәзерге вакытта Россия банкының кисәтү исемлегендә 7 мең компания исәпләнә. Шуларның 60тан артыгы Татарстанда да эшли.

«Кара» кредиторлар, ягъни легаль булмаган кредиторлар белешмәләрсез һәм кредит алганда кирәкле булган икенче затларсыз гына бурычка акча тәкъдим итә. Алай гына да түгел, алар бурыч түләтүнең хокукларга каршы килә торган ысулларын да куллана. Шуңа да мондый кредиторлардан аеруча сак булырга кирәк.

Атна ахырына Татарстанда һава температурасының сизелерлек төшүе көтелә. Бу турыда Татарстанның Гидрометүзәге хәбәр итә. Әйтик, бүген төнлә һава температурасы +2...–3 градусны тәшкил итәчәк. Синоптиклар фаразларына караганда, томан булуы ихтимал. Шимбә һәм якшәмбе, 22 һәм 23 октябрьдә, Татарстанда явым-төшем көтелми. Төнге сәгатьләрдә температура 0...–7 градусны, көндез +1...+7 градусны тәшкил итәчәк.

Синоптикларның фаразларына караганда, киләсе атна башында Татарстанда явым-төшемнәр көтелә. Температура исә көндезге сәгатьләрдә дә +2...+7 градустан югары күтәрелмәячәк.

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ:

«КЫЕНЛЫКЛАРНЫ БЕРГӘЛӘП ҖИҢӘ БАРАБЫЗ»

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫНЫҢ 2023 ЕЛГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНА ЮЛЛАМАСЫ



tatarstan.ru

Хөрмәтле Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары һәм утырышта катнашучылар!

Кадерле ватандашлар!

Чыгышымны Татарстанның халык шагыйре Мөдәррис Әгъләмов ярты гасыр элек язган сүзләрдән башлыйсым килә.

Бер канатың була туган телең,
Бер канатың була туган җир;
Кошка гына түгел, кешегә дә
Канат кирәк була торгандыр.

Син чыннан да, илем, әкияттәге
Чабып барган атка охшаган.
Шушы ике канат бар чагында,
Киләчәккә, илем, ышанам.

Туган тел, туган җир, рухи-әхлакый традицияләребез, бай тарихи-мәдәни мирасыбыз, милләтара һәм динара татулык һәм тынычлык – болар барысы да бездә горурлык хисе тудыра, аерым игътибар һәм әһәмият бирелә торган рухи хәзинәләр булып тора һәм киләчәктә дә, һичшиксез, шулай булачак.

Бүгенге көндә Татарстан – күпмилләтле Россиянең алгарышлы төбәкләреннән берсе. Югары квалификацияле кадрлары, куәтле җитештерү комплексы, алдынгы инфраструктурасы, Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм шәхсән Россия Федерациясе Президенты Владимир Владимирович Путинның ярдәме нәтиҗәсендә республика бүген дә тотрыклы социаль-икътисади үсештә.

Без кешеләрнең тормышын яхшыртуга юнәлтелгән социаль гарантияләрне тәэмин итәбез, ниятләнгән илкүләм проектларны һәм республика программаларын гамәлгә ашырабыз.

Күпмилләтле Ватаныбыз белән бергәләп без бүгенге кыенлыкларны җиңә барабыз. Махсус хәрби операция уздыру шартларында Татарстанда хакимиятнең барлык дәрәҗәләре һәм тармаклары, парламент партияләре, иҗтимагый берләшмәләр, ил җитәкчелегенә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә шиксез хуплау белдереп, килештерелгән эшчәнлек алып бара. Азат ителгән Донецк һәм Луганск халык республикаларының, Херсон һәм Запорожье өлкәләренең Россия Федерациясе белән яңадан кушылуы барыбыз өчен дә тарихи һәм озак көтелгән вакыйга булды. Суверенлыгыбызны һәм гражданнарыбызны яклауны тәэмин итәчәгебезне без бөтен дөньяга ачык күрсәттек. Бөтен ил батыр сугышчыларыбыз һәм Югары Башкомандующий Владимир Владимирович Путин тирәсендә тупланды. Россия Кораллы Көчләре солдатлары һәм офицерлары – алар арасында Татарстан Республикасында туган һәм тәрбияләнгән сугышчылар – Россиянең имин киләчәген саклау буенча изге бурычларын үти. Без җиңәчәгебезгә ышанабыз!

Ватанга һәм халыкка хезмәт итү юлын сайлаган сугышчыларыбызның кайберләре тынычлыкны гомерләрен корбан итү бәрабәренә саклады. Каһарманнарыбызның тиңдәшсез батырлыгы һәм кыюлыгы мәңге онытылмас. Махсус хәрби операциядә һәлак булган һәркемне бер минут тынлык белән искә алырга тәкъдим итәм.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Республиканың дәүләт һәм муниципаль хакимияте органнарына, оешмалары һәм предприятиеләренә Россия Федерациясе Президенты Владимир Владимирович Путин куйган бурычларны тулы күләмдә үтәүне тәэмин итәргә кирәк.

Илдә өлешчә мобилизация бара. Сугышчыларыбызга һәм аларның гаиләләренә адреслы ярдәм күрсәтү һәм алар турында кайгырту таләп ителә. Бик күпләргә җиңел түгел хәзер. Ярдәм итәргә телəгəн предприятиеләрнең, иҗтимагый оешмаларның, татарстанлыларның саны арта баруын күрәбез. Мондый башлангычларны төрлечә хупларга кирәк.

Республика күләмендә «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» хәрәкәте кысасында халыкка төрлечә булышлык күрсәтелә. Башлыкларның бурычы – җирлекләрдә һәрьяклап ярдәм оештыру.

Шулай ук Россия Федерациясенең яңа субъектлары халкына гуманитар ярдәм күрсәтү эшен дәвам итәргә кирәк. Татарстан торгызу эшләрендә, мохтаҗларга ярдәм күрсәтүдә актив катнаша. «КАМАЗ», «Татнефть», «Татхимфармпрепараты», «Нәфис», «Газпром трансгаз Казан», Чаллы катыргы-кәгазь комбинаты, Казан авиация заводы, Казан вертолет заводы һәм башка предприятиеләр уртак эшкә зур өлеш кертә.

Бу эштә барлык муниципалитетларыбыз катнаша. Тәтеш районы башлыгы Рәмис Хатыйп улы Сафиуллов, шулай ук Мөслим районыннан эшкуар Илгиз Зәкиҗан улы Исламов турында аерып әйтергә телим. Һәм мондый кешеләр республикада күп. Ярдәмегез өчен һәрберегезгә рәхмәтемне җиткерәм. Без бу эшне дәвам иттерәчәкбез.

> Дөньядагы хәзерге катлаулы хәлләр күп нәрсәгә ачыклык кертте һәм бер караганда гади кебек тоелган төшенчәләр – гаилә, балалар, Ватанга мәхәббәт, ватанпәрвәрлек, ата-бабалар мирасы – беренче урынга чыкты. Илебез тарихы батырлык һәм кыюлык үрнәкләренә бик бай. Буйсынмаган, фидакарь җиңүчеләр буыны – безнең горурлыгыбыз.

Республика Хөкүмәтенә, муниципаль берәмлекләр башлыкларына Ватанны саклап көрәшкән, шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашкан каһарманнар турындагы хәтерне мәңгеләштерү эшен дәвам итү зарур.

Бөек Ватан сугышы чорында тыл хезмәтчәннәренең батырлыгы һәм фидакарьлеге турындагы истәлекне мәңгеләштерү максатларында «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме гамәлгә куелды. Татарстанның 17 предприятиесе әлеге зур бүләккә лаек булды.

Җиңүнең данлыклы традицияләрен саклау яшь буынга патриотик тәрбия бирүдә гаять зур әһәмияткә ия. Барлык мәгариф һәм мәдәният учреждениеләре эшчәнлегенең шуңа юнәлтелгән булуы шарт. «Авангард» хәрби-патриотик тәрбия үзәкләре, хәрби-патриотик клублар, балалар һәм яшьләр берләшмәләре аеруча зур роль уйнарга тиеш. Патриотик тәрбия бирү буенча республика координация советына бу эшчәнлекне методик яктан тәэмин итүне йөклим. Программа чараларын уздырганда, «Җиңү волонтерлары» корпусын киңәйтүгә һәм, тулаем, ирекләләр хәрәкәтен үстерүгә аеруча игътибар бирү зарур. Илебез һәм халкыбыз өчен

башкарылган игелекле эшләр – яшь буында ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләүнең нигезен нәкъ менә шулар тәшкил итә.

Гомумән алганда, бүген безнең алда рухи хәзинәләрнең тулаем бер системасын булдыру, тәрбия эшен камилләштерү, илкүләм иҗтимагый институтларны үстерү буенча җитди бурычлар тора.

Үз иленең патриоты булу – Ватанын, туган телеңне ярату, мәдәниятеңне кадерләү, үткәнеңне хөрмәт итү дигән сүз. Балаларга һәм яшьләргә патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбия бирү – дәүләтнең иң мөһим бурычы. Ватаныбыз иминлеге сагында нәкъ менә киләчәк буыннар торачак.

Хөрмәтле депутатлар!

Медиакиңлектәге җитди үзгәрешләр, Россиягә моңарчы күрелмәгән басым ясалу, санкцияләр кертелү, провокацияле төрле темалар һәм яңалыклар таратылу бүген бездән дөрес чаралар күрүне таләп итә.

Чынбарлыктагы вакыйгаларга аңлатма бирү, дөреслеге расланмаган һәм ялган мәгълүматларны таратуга юл куймау, хак фикерләрне һәм ачыкланган фактларны халыкка җиткерү – мәгълүмат блогының, массакүләм мәгълүмат чараларының иң әһәмиятле бурычы.

Бүгенге көндә мәгълүмат мәйданындагы мәсьәләләр, берничә ел элек булган вазгыять белән чагыштырганда, гомумән, күпкә киңрәк һәм катлаулырак. Республика Хөкүмәтенә мәгълүмат өлкәсендәге дәүләт сәясәтен камилләштерүгә кагылышлы тәкъдимнәр, дәүләт массакүләм мәгълүмат чараларын заман куйган бурычлар һәм таләпләр нигезендә яңартып коруны башкару буенча тәкъдимнәр эшләүне йөклим.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Милләтара, динара һәм гражданнар арасындагы татулык һәм тынычлык безнең өчен һәрчак иң мөһим рухи хәзинәләрнең берсе булды һәм шулай булып кала да.

Бу ел республикада Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу белән истәлекле булды. Илебез Президенты Владимир Владимирович Путинның йөкләмәсе буенча әлеге юбилей датасы федераль дәрәҗәдә дә билгеләп үтелә. Бик күп әһәмиятле проектлар тормышка ашырыла. Чаралар күпсанлы кунаклар, шул исәптән чит ил вәкилләре катнашында уза. Болар барысы да мөселман илләренең Россия Федерациясе белән үзара файдалы хезмәттәшлекне үстерүгә кызыксынуы артуына дәлил булып тора.

Без юбилейны әзерләү һәм уздыруга һәрьяклы ярдәм күрсәткәннәре өчен Михаил Владимирович Мишустин җитәкчелегендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенә, оештыру комитеты рәисе Марат Шакирҗан улы Хөснуллинга, илебезнең мөселман дини берләшмәләре җитәкчеләренә чиксез рәхмәтлебез.

Татарстан митрополиясенең рухи тормышы шулай ук вакыйгаларга гаять бай булды. Быел Рус Православие Чиркәвенең 20 архиерее катнашында Казан Мәрьям Ана иконасы соборын изгеләндерүгә бер ел тулу уңаеннан бәйрәм чаралары уздырылды. Алар республикабыздагы дәүләт-конфессияара бәйләнешләрнең тиешле югары дәрәҗәдә булуын ачык күрсәтте. Россиядәге православие дини уку йортларының иң күренеклеләреннән берсе булган Казан дини семинариясенең 300 еллыгын бәйрәм итү киләсе елның истәлекле вакыйгасы булачак.

Республикада милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салуга Татарстан халыклары ассамблеясы, Халыклар дуслыгы йортлары һәм этномәдәни берләшмәләр үзләреннән зур өлеш кертә.

Туган телгә һәм мәдәнияткә игътибар бөтен дөнья татарларын берләштерә. Быел без Бөтендөнья татар конгрессының 30 еллыгын билгеләп үттек. Бу вакыт эчендә конгресс тормышчан булуын исбатлады, телне, милли мәдәниятне һәм гореф-гадәтләрне саклау, халкыбызны берләштерү буенча зур эш башкарды.

Бүгенге көндә этноконфессиональ өлкәдә инде күп еллар дәвамында безнең тарафтан башкарыла торган эш җитди сынауга дучар булды. Тышкы көчләр безнең халыкларның бердәмлеген, ныклыгын сыный – алар милли хисне үз мәнфәгатьләрендә файдаланырга омтыла. Татарстан да җентекле игътибар үзәгендә. Безнең уртак бурычыбыз – әлеге хәлне булдырмау һәм илкүләм лидерыбыз Владимир Владимирович Путинга ышаныч белдереп, тагын да берләшү.

> Республикабызда зур гаилә булып яшәүче төрле милләт вәкилләре арасында үзара ихтирамлы мөнәсәбәт, халыкларның телләрен, мәдәниятләрен һәм гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү – безнең иң зур казанышыбыз!

Татарстанда гомер итүче халыкларның тарихи-мәдәни мирасы зур һәм бай. Рухи хәзинәләребезне саклау һәм үстерүнең, ата-бабаларыбыздан калган милли гореф-гадәтләребезне торгызуның гаять зур әһәмияткә ия булуын исәпкә алып, шулай ук Россия халыклары мәдәни мирасы елының дәвамы буларак, 2023 елны республикада Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан итәм.

Төрле чорларда борынгы гореф-гадәтләребезнең сагында нык гаилә тора. Ул – көчле дәүләтнең нигезе, буыннар арасындагы җанлы бәйләнеш, балалар тууны һәм халык санын арттыруның мөһим шарты.

Татарстанда күркәм гаиләләр бик күп: алтын һәм бриллиант туйларын билгеләп үтүче парлар, күпбалалы, тәрбиягә бала алган гаиләләр, иҗат белән шөгыльләнүче һәм спорт сөюче династияләр.

Массакүләм мәгълүмат чараларында традицион гаилә кыйммәтләре, ата-ана булуның җаваплылыгы, күпбалалы гаиләләр турында тагын да күбрәк мәгълүмат бирү, аларның тормыш тәҗрибәсе белән уртаклашу – безнең бурычыбыз.

Аерылышуларга, иң беренче чиратта, балалары булган гаиләләргә кагылышлы әлеге мәсьәләгә аерым игътибар бирергә кирәк. Күпчелек очракларда мондый карарлар тирәнтен уйламыйча, хисләргә бирелеп кабул ителә. Суд карары кабул ителгәнгә кадәр мөнәсәбәтләрендә аңлашылмаучанлыклар килеп чыккан парларга ярдәм итәргә, аларга гаиләләрен саклап калуда һәрьяклап булышлык күрсәтергә кирәк.

Гаилә – безнең өчен иң зур байлык. Ул – бер-беребезне яратырга һәм хөрмәт итәргә өйрәтә, безгә барлык авырлыкларны җиңәргә көч бирә. Нәкъ менә гаиләдә әхлакый һәм рухи кыйммәтләр, милли һәм мәдәни традицияләр тапшырыла. Балалы гаиләләргә булышу безнең өчен һәрвакыт мөһим булды һәм булачак.

Хөрмәтле депутатлар!

Республиканың үсеше өчен мөһим этәргеч – ул татарстанлыларның идарәгә бәйле карарлар кабул итүдә катнашуы.

Гражданлык җәмгыятенең иң нәтиҗәле эшләүче институты – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы. Безгә аның яңа җиденче составын формалаштырырга кирәк булачак. Шунысы гаять мөһим: анда тиешле тәҗрибәсе һәм белеме булган гражданнар кертелергә тиеш.

Дәүләтнеке булмаган секторны, аеруча социаль өлкәне үстерүгә булышлык күрсәтү – безнең мөһим бурычларыбызның берсе.

Быел республикада проектларны үтәүгә ярдәм итүнең бердәм грант операторы механизмы, «Юстиция кварталы» кысаларында иҗтимагый ресурс үзәге булдырылды, «Игелекле Казан» коворкингы эшен дәвам итә.

Халык белән хезмәттәшлек итүнең нәтиҗәлелеген арттыруда шәһәр, район һәм авыл дәрәҗәсендәге муниципаль хакимият органнары зур роль уйный. Җирле үзидарәләрнең бурычы – даими рәвештә үзләренең эшләрен камилләштерә килеп, гражданнарның үсә барган ихтыяҗларын канәгатьләндерү мөмкинлегенә ия булу. Җирле үзидарә – ул туган җирләрен ихлас яратучы, битараф булмаган, үз шәһәрләре һәм районнары, авыллары һәм бистәләре үсеше өчен җаваплылыкны үз өсләренә алырга әзер торучы кыю кешеләр.

Без бүген шушы залга үз вазыйфаларында 20 елдан артык эшләүче авыл башлыкларын чакырдык. Алар: Мөнир Туктаров, Нина Котельникова, Виктор Кормачев, Җәлил Гайфетдинов, Радик Ибраһимов һәм Эдуард Гәрәев. Хөрмәтле хезмәттәшләр! Сезгә һәм җирле үзидарә системасының барлык хезмәткәрләренә гаять мөһим һәм кирәкле эш башкаруыгыз өчен рәхмәт сүзләремне җиткерәм.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Халыкара һәм тышкы икътисади эшчәнлек зур үзгәрешләр кичерә, аны хезмәттәшлек алып баруның яңа шартларына һәм рәвешләренә яраклаштыру зарур.

Безнең алда перспективалы юнәлешләр буенча хезмәттәшлекнең яңа чикләрен формалаштыру бурычы тора. Күп еллар дәвамында Татарстанда Ислам хезмәттәшлеге оешмасына кергән илләр белән күпкырлы элемтәләрне үстерүгә аерым игътибар бирелә. Узган ел Казан шәһәренә Ислам хезмәттәшлеге оешмасының яшьләр башкаласы дигән статус бирелү халыкара диалогка яшьләрне җәлеп итү өчен яңа мөмкинлекләр ача. Алардан файдалану гаять мөһим.

Республика шулай ук «Россия – ислам дөньясы» стратегик караш төркеме форматында актив эш алып бара. Аның кысасында Татарстанның башкаласында җәй көне KazanSummit 13 нче халыкара икътисади саммиты узды, анда дөньяның 64 иленнән һәм Россиянең 59 төбәгеннән 6500 кеше катнашты. Россия Федерациясе Президенты Владимир Владимирович Путин чараны оештыру дәрәҗәсен югары бәяләде һәм безнең форумга федераль статус бирү турындагы тәкъдимебезне хуплады. Бу – безгә гаять зур ышаныч белдерү һәм шул ук вакытта зур җаваплылык та. Петербург шәһәрендә уза торган һәм Көнчыгыш икътисади форумнар белән беррәттән Казан, тигез хокуклылык шартларында үзара файдалы халыкара хезмәттәшлек алып бару кысасында, Россиянең икътисади мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча зур мәйданчыкларның берсе булып тора.

Финанс ресурсларыннан файдалануга чикләүләр кертелгән бүгенге көн шартларында ислам илләре финанслары институтын үстерү безнең өчен мөһим юнәлеш булып тора. Әлеге вакытта федераль дәрәҗәдә законнар базасын формалаштыру эшләре тәмамланып килә. Татарстан – пилот төбәкләр арасында. Яңа чаралардан файдалану икътисадның финанслар җәлеп итү мөмкинлекләрен арттыра. Алардан күбрәк кулланырга кирәк.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Барлык программаларыбызны үтәүнең, халыкның тормышын яхшыртуның һәм муллыкның нигезен нәтиҗәле икътисад тәшкил итә.

Быел предприятиеләребез тышкы сәүдәдә чикләүләр, логистика бәйләнешләренең чуалуы, Көнбатыш технологияләренә һәм кредит ресурсларына юллар ябылу кебек кыенлыклар белән очрашты. Шулай да узган елларда корылган нигезнең ныклыгы, предприятиеләр һәм компанияләрнең өзлексез эшләве, кредит

Фәрит МӨХӘММӘТШИН,
Татарстан Дәүләт Советы Рәисе:
– Мобилизация һәм чикләүләр Татарстанныкы кебек күп юнәлешле икътисадка зур йогынты ясый. Минемчә, республикага аның лидеры – Рөстәм Миңнеханов тирәсендә берләшергә кирәк. Шул очракта барлык бурычларны да уңышлы үтәячәкбез. Юллама эчтәлекле иде. Безнең эшкә дә бәя бирелде. Депутатлар хәзер куелган бурычларны тормышка ашыру өчен көч куячак. Президент игълан иткән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елына бәйле эшләрне дә бүгеннән үк башларга кирәк. Бу – күпмилләтле, күптелле, күпконфессияле Татарстан өчен фундаменталь кыйммәтләр.

Александр ТЕРЕНТЬЕВ,
Россия Федераль Җыенының Федерация Советы әгъзасы:
– Президентның Дәүләт Советына Юлламасында республиканың үсеш этабы һәм киләчәккә бурычлары төгәл билгеләнде. Ә иң мөһиме – Юллама кешегә юнәлтелгән иде. Һәр максат һәм бурычның үзәгендә кеше торды. Һәм Рөстәм Миңнехановның сүзләрендә хәзерге вакытта җәмгыять өчен гаять мөһим булган ныклы ышаныч хисе сизелде.
Юлламада тагын бер мөһим мәсьәлә – традицион рухи кыйммәтләргә зур игътибар бирелде. Президент гаилә, тарихи-мәдәни мирас, төрле милләт һәм дин вәкилләре арасындагы мөнәсәбәтләр кебек мөһим мәсьәләләргә аерым тукталды. Алар республика үсешен тәэмин итә торган төп кыйммәтләр булып тора. Рөстәм Миңнехановның 2023 елны республикада Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан итүе моны кабаттан раслады.
Моннан тыш, Юлламада икътисади сорауларга да зур игътибар бирелгән иде. Президент бүгенге сынауларга җавап бирә торган икътисади чараларны тәгаенләде, республикада гамәлгә ашырылган масштаблы проектлар турында сөйләде. Шушы мисаллар безгә тагын бер кат республиканың үсеше тотрыклы булуын исбатлады. Президент әйтүенчә, әлеге үсешнең нигезе – күп еллар дәвамында тупланган икътисади, сәнәгать потенциалы, югары профессиональлеккә ия булган кадрлар, уңышлы гамәлгә ашырылган федераль программалар. Билгеле, бу безнең күңелләргә ышаныч өсти. Президентның әлеге чыгышын тыңлаганнан соң, Татарстан халкында да бу ышаныч артсын иде.

Марат ӘХМӘТОВ,
Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе:
– Президент Юлламасында яңгыраган һәр тезис бик мөһим. Бик җентекләп әзерләнгән һәм киләчәккә юнәлеш ала торган стратегик документ бу. Нинди генә киеренке, ил язмышына бәйле халәт булуга карамастан, Президентыбыз республикабызның икътисады тотрыклы булуын билгеләп үтте. Бу – безнең ныклык запасыбыз бар дигән сүз һәм республиканың бу максатка бик нык йөз тотуы турында сөйли. Туган телләр комиссиясе җитәкчесе буларак, Президентыбызның үз чыгышын шушы мәсьәләдән башлап җибәрүе күңелемә аеруча хуш килде. Президентыбызның тел, милләт язмышына шулай җаваплы каравы безгә бик кирәк һәм бик булыша. Киләсе елыбыз да Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителә икән, телебез язмышын куәтләп эшләргә тагын бер сәбәп, зур этәргеч бар дигән сүз. Гомумән алганда, быелгы Юлламаны конкрет юнәлешле, һәр тармакны исәпкә алган, республикабызның киләчәген ачык күреп, барыбызны да шушы максатны үтәүгә чакыра торган документ дип кабул итәм.

һәм финанс оешмаларының нәтиҗәле эшчәнлеге, илкүләм проектларны гамәлгә ашыру, федераль дәрәҗәдәге һәм төбәктәге ярдәм чаралары нәтиҗәсендә республиканың икътисады читтән басымнарга бирешми торган тотрыклы булып чыкты.

Быелның эш йомгаклары буенча тулай төбәк продукты чама белән 3,7 трлн сум, төяп озатылган продукт күләме 4,4 трлн сум, төзелеш эшләре күләме 460 млрд сумнан артып китәчәк, төп капиталга инвестицияләр 750 млрд сум тәшкил итәчәк.

> Иң мөһиме, халыкның эш белән тәэмин ителүен саклап кала алдык һәм эшсезлекнең артуын булдырмауга ирештек. Моның өчен предприятиеләребез җитәкчеләренә һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары күргәне өчен федераль Хөкүмәткә рәхмәт сүзләремне җиткерәсем килә.

Нефть, газ һәм химия комплексы республика икътисадының нигезен тәшкил итә. Без «Татнефть» компаниясенә нефть чыгаруда һәм эшкәртүдә чит ил товарларын алыштыру эше белән системалы шөгыльләнгәне, чит илләр тудырган кыенлыкларны җиңүдәге уңышлары өчен рәхмәтебезне белдерәбез. Бу – эшне илебез технологияләрен һәм җиһазларын файдаланып оештыруның бер мисалы.

Кече нефть компанияләре нәтиҗәле эшләүләрен күрсәтте. Аларны оештыру турындагы карарны Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев 25 ел элек кабул иткән иде. Шул вакыт эчендә республикада нефть чыгару эшендә бу кече компанияләрнең өлеше 3 проценттан 20 процентка күтәрелде.

Ел йомгаклары буенча Татарстанда якынча 36 млн тонна нефть чыгару каралган.

«ТАНЕКО» комплексында нефть чималын кабул итү һәм эшкәртү буенча җиһазларның башлангыч куәтен елына 16,3 млн тоннага кадәр арттыру (мазут җитештерүдән тыш), быел дүрт яңа җайланманы файдалануга кертү юнәлешендә зур эш башкарыла.

«ТАИФ-НК» шулай ук нәтиҗәле эшли. Болар һәммәсе чимал эшкәртүне 23 млн тоннага җиткерергә мөмкинлек тудырачак.

Нефть, газ, химия комплексы тотрыклы үсештә.

«СИБУР» компаниясе «Түбән Кама нефтехим» һәм «Казан органик синтез» предприятиеләрендә этилен һәм поликарбонат заводларын яңартып кору, электр энергиясен җитештерү җайланмалары төзү кебек инвестиция проектларын гамәлгә ашыруны дәвам итә.

2024 елда ЭП-600 олефиннары җитештерү буенча яңа комплексны сафка кертү планлаштырыла.

Моннан тыш, «СИБУР» һәм «Алабуга» махсус икътисади зонасы Түбән Камада индустрия паркын ачу турында килешү төзеде. «Түбән Кама нефтехим» чыгара торган продукциянең төрлелеге арадаш тармакларда җитештерүне үстерү өчен киң мөмкинлекләр ача. Без «СИБУР» компаниясенә җитди ниятләре өчен рәхмәтебезне җиткерәбез һәм республикада җитештерү предприятиеләрен үстерү хакына ярдәм күрсәтергә әзер булуыбызны белдерәбез.

«Газпром» компаниясе – безнең стратегик партнерыбыз. Татарстанда газ куллану күләме узган елда 18,2 млрд куб. м тәшкил итте. Һәм бу күрсәткеч ел саен арта бара.

Газ-мотор ягулыгы базарын үстерү буенча уртак проектны гамәлгә ашыру уңышлы дәвам итә. Татарстанда 37 газ ягулыгы салу станциясе, 3 крио автомобиль ягулыгы салу станциясе урнашкан, тагын 9 ягулык салу станциясен төзү эшләре алып барыла. Моннан тыш, быел газ сыекландыру буенча ике завод эшли башлады. «Газпром» компаниясенә республиканың башлангычларында ярдәм күрсәткәне өчен рәхмәт сүзләремне белдерергә телим һәм киләчәктә дә бергә нәтиҗәле эшләрбез дип ышанам.

Көнкүреш химиясен җитештерүче зур чит ил компанияләренең илебездән китүе белән бәйле рәвештә «Нәфис» компаниясенә продукциясен сату базарын киңәйтү өчен яңа мөмкинлекләр ачыла.

«Алабуга» махсус икътисади зонасындагы «Данафлекс» компаниясе кабаттан эшкәртеп була торган яңа төр пленка материаллары җитештерү буенча 2,5 млрд сумлык проектны гамәлгә ашыра.

KAMA TYRES компаниясе шиннар җитештерүне яңартып кору һәм продукцияне төрлеләндерү эшен дәвам итәрә. Быел предприятие проектларына инвестицияләр кертү күләме 7 млрд сум тәшкил итәчәк.

Машина төзелеше өлкәсендә КАМАЗда җитештерү күләмнәрен саклап калуга юнәлтелгән эш алып барыла. Предприятие модельләрне арттыруны дәвам итә. Киләсе елның I кварталында автомобильләр җитештерүче бу зур завод сыйфаты яхшыртылган, чит ил товарларын алмаштыру программасы тулысынча тәгәлләнгән яңа буын К5 йөк машиналарының тулы бер модельләр сафын җитештерә башлаячак.

Бу елның ахырына кадәр Алабугада «Соллерс» компаниясе яңа коммерцияләр автомобильләр эшләп чыгара башлаячак.

«РИАТ» компаниясе яңа манипуляция краннары чыгарырга әзерләнә.

Казан авиация заводын яңартып кору эшләре дәвам итә. Предприятие алдында гражданнар өчен Ту-214 очкычларын серияле рәвештә җитештерүне елына 20 очкычка җиткерү бурычы тора. Республика заказчысы белән 4 очкычка контракт төзелде инде.

Казан вертолет заводы киләсе елда «Ансат» вертолетларын җитештерүдә чит ил товарларын алмаштыру программасын тәмамлауны планлаштыра. Барлык модельләр буенча җитештерү күләмен елына 100 вертолеттан да кимрәк булмаслык итеп саклап калу мөһим.

Зеленодольскиның А.М. Горький исемендәге заводы быел беренче «Метеор»ны куллануга тапшырды. Ул пассажирлар флотын торгызуны тәэмин итәргә тиеш. Республиканың судагы маршрутларында йөртү өчен тагын өч яңа көймә – ике «Метеор» һәм бер А-217 көймәләрен төзүгә заказ бирелде.

Ростех компаниясенең ярдәме белән «ПОЗиС» оешмасы дәүләт корпорациясенең барлык предприятиеләре өчен стандарт булмаган җиһаз җитештерү буенча бердәм үзәк итеп билгеләнде.

Гомумән алганда, Татарстанда Ростехның 15 предприятиесе уңышлы эшчәнлек алып бара, анда эшләүчеләр саны 50 мең кешедән артып китә. Дәүләт корпорациясенә, шәхсән аның генераль директоры Сергей Викторович Чемезовка нәтиҗәле хезмәттәшлегебез өчен рәхмәт белдерәм.

Зур компанияләр белән беррәттән, Чистайда «Бетар» компаниясе робот-манипуляторлар җитештерү буенча яңа мәйданчык ача, «Меттэм» компаниясе автомобильләр төзү тармагы өчен электр компонентларын җитештерүне башлап җибәрә, Бөгелмәдә «НТЭС» компаниясе кече төягечмашиналар чыгаруны җайга салды.

Ихтыяҗ зур булган продукция җитештерә торган предприятиеләр бездә күп. Аларның һәрберсе республика икътисадын үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә.

Хөрмәтле депутатлар!

Илебез Президенты Владимир Владимирович Путин гаскәрләрне заманча яңа корал һәм техника белән тәэмин итүне кыска вакыт эчендә арттыру бурычын куйды.

Бүгенге көндә республиканың оборона-җитештерү комплексы предприятиеләре аны үтәүдә катнашалар һәм дәүләтебез иминлеген тәэмин итүгә зур өлеш кертәләр.

> Шул ук вакытта файдаланылырга тиешле мөмкинлекләр тагын да бар әле. Булган җитештерү куәтләрен тулысынча эшләтергә, продукция эшләп чыгару күләмен арттырырга кирәк. Иң мөһиме – дәүләтнең оборона өлкәсендәге заказын вакытында үтәүгә ирешү.

Илебезнең саклануга сәләте күпчелек очракта технологик суверенлыгыбызны тәэмин итүгә бәйле булуы шик уятмый. Фәнни оешмаларның һәм югары уку йортларының икътисадның реаль секторы белән хезмәттәшлеген арттыру гаять мөһим. Бу юнәлештә эшчәнлек алып барганда КФУ, «Иннополис» университеты һәм КФТТУ (КХТИ) базасында булдырылган алдынгы инженерлык мәктәпләренә, КФТТУ-КАИ гамәлгә ашыра торган «Крылья Ростеха» махсус проектына, шулай ук республика югары уку йортлары базасында технологик эшкуарлык стартап-студияләренә таянырга кирәк.

Бу проектларда катнашулары өчен индустриаль хезмәттәшләребезгә – «СИБУР», Ростех, Росатом, Роскосмос компанияләренә, Урал граждан авиациясе заводына, «Газпром» һәм КАМАЗ предприятиеләренә рәхмәт сүзләремне җиткерәм.

Моннан тыш, технологик бәйсезлеккә ирешү һәм икътисадның төп секторларының критик мәгълүмати инфраструктурасы куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен республика предприятиеләренә илдә булдырылган программа тәэминатына һәм үзебезнең җиһазларга мөмкин булганча күбрәк күчәргә кирәк.

Исәпләү техникасын җитештерү буенча яңа производстволар булдыру актуаль. ICL компаниясе «Иннополис» махсус икътисади зонасы белән бергәләп елына 1 млн эшләнмә җитештерә торган төп платалар заводын төзүгә керешә. Бу – илебездәге барлык микроэлектроника җитештерү өлкәсе өчен зур вакыйга.

Кадрлар әзерләү системасын җитештерүчеләр ихтыяҗларына җайлаштырырга кирәк. «Алабуга Политех» эшче белгечләр әзерләү үзәге эшчәнлеге (монда студентларны «Алабуга» махсус икътисади зонасы заводлары инженерлары заманча җиһазларда эшләргә өйрәтә), шулай ук Әлмәт һөнәр көллиятенең «Римера – Алнас» компаниясе белән, КАМАЗның В.Д. Поташов исемендәге техник көллият белән, Казан авиация-техник көллиятенең оборона-җитештерү комплексы предприятиеләре белән хезмәттәшлеге бу өлкәдә үрнәк булып тора.

Соңгы 8 елда республикада кадрлар әзерләү буенча 45 ресурс үзәге ачылды, алар төп предприятиеләр белән актив хезмәттәшлек итә. Бу эш системалы алып барылырга һәм теләсә кайсы тармак өчен кадрлар җитештерүнең аерылгысыз өлешен тәшкил итәргә тиеш.

Югарыда әйтелгән барлык бурычлар эшләнә торган стратегиядә һәм республиканың фәнни-технологик үсеше программасында чагылыш табарга тиеш.

Гомумән алганда, планнарыбызны һәм проектларыбызны гамәлгә ашыру өчен безгә инвестицияләр җәлеп итүдә активлыкны арттыру һәм эшлеклелек тирәлеген камилләштерү эшен дәвам иттерергә кирәк.

Бизнеска инвестицияләр проектлары белән бәйле барлык процедуралар уздыруның ачыклыгын тәэмин итәргә кирәк.

Өстәвенә аларның санын киметүгә һәм мөмкин булганча карарлар кабул итү вакытын кыскартуга ирешү зарур. Булган барлык дәүләт ярдәме чараларын күбрәк файдаланырга кирәк. Алар арасында – капитал салу эшләренең куркынычсызлыгын саклау һәм аларга ярдәм күрсәтү буенча килешүләр төзү механизмын яңадан эшләтеп җибәрү, алгарышлы үсеш территорияләре преференцияләрен үстерү, кирәкле инфраструктураны булдыру.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1119 номерлы карары кысасында «Алабуга» һәм «Иннополис» махсус икътисади зоналары идарә компанияләренә индустриаль парклар төзү буенча бурлык оештыру чараларын тиз арада тәгәлләргә һәм аларда резидентлар эшләвен тәэмин итәргә кирәк.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Кече һәм урта бизнес өлешенә республикадагы эш урыннарының 41 проценты туры килә. Бүгенге көндә эшкуарларга чынбарлыктагы шартларга тизрәк җайлашырга, базарда эшчәнлек алып бару өчен барлыкка килгән яңа юнәлешләрне киңрәк үзләштерергә кирәк.

> Татарстан җитештерүчеләренә, шул исәптән муниципаль сәнәгать парклары мөмкинлекләреннән дә файдаланып, ярдәм күрсәтү – безнең бурычыбыз. Бу – районнарда яңа эш урыннары булдыру, урта һәм кече эшкуарлыкны үстерү өчен төп мөмкинлек. Аларны сыйфатлы итеп үстерү бүген зур әһәмият ала.

Сәнәгать паркының уңышлы эшләве нәтиҗәле идарәче компаниянең, резидентларның булуыннан, яңа җитештерү предприятиеләре урнаштыру өчен инфраструктура белән тәэмин ителгәнлектән, шулай ук район башлыкларының инвесторлар җәлеп итүдә кызыксынган булуыннан тора.

Шул ук вакытта муниципаль сәнәгать паркларының барысы да әлеге таләпләргә җавап бирми. Без Инвестиция-венчур фондының һәм республика Инвестицион үсеш агентлыгының үзләренә беркетелгән сәнәгать парклары буенча эшләрендә конкрет нәтиҗәләр күрмибез.

Ә бит безнең уңышлы эшли торган «Химград», КИП «Мастер», «Үсеш Чаллы», «Зеленодольск» паркы, «Саба» паркы, «Теләче», «Алексеевск», «М-7» һәм кайбер шундый башка мәйданчыкларыбыз бар.

Республиканың Икътисад министрлыгына муниципаль районнар башлыклары, нәтиҗәле эшләүче сәнәгать парклары идарәче компанияләре белән бергәләп яхшы тәҗрибәне мөмкин булганча күбрәк таратырга, яңа инвесторлар җәлеп итүдә яңа шартлар булдыру өчен сәнәгать паркларын үстерүгә киртә булган факторларны бетерү буенча эшне дәвам итәргә кирәк.

Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен баштан ук бизнестагы башлангычларга мөмкин кадәр иртәрәк ярдәм күрсәтү зарур. Яшь эшкуарларга грант ярдәме күрсәтү, шулай ук үзмәшгульләр институтын камилләштерү эшен дәвам иттерергә кирәк. Республикада бүгенге көндә аларның саны 215 меңнән артып китә. Үзмәшгульләр җитештерә торган продукцияләрен сатсын өчен ярминкәләр оештыруны дәвам итү мөһим.

Тулаем алганда, продукция сату базарларын киңәйтү өчен Республика маркетинг үзәге һәм электрон сәүдә мәйданчыклары мөмкинлекләреннән активрак файдалану уңышлы булачак.

Электрон сәүдәне үстерү программасыннан файдаланулары нәтиҗәсендә Татарстан эшкуарларына үз продукцияләр-

рен сату өчен, шул исәптән республикадан читтә дә, мөмкинлекләр ачылды. Ел башыннан алып исәпләгәндә генә дә маркетплейсларда товар сату күләме ике тапкыр артты һәм сатучыларның саны 40 меңнән артып китте. Программаны гамәлгә ашыруны алдагы елларда да дәвам иттерергә кирәк.

«Вайлдберриз» компаниясе – Татарстандагы иң зур маркетплейсларның берсе – республика икътисадына 5 млрд сумнан артык инвестиция кертте, 7 меңнән артык эш урыны булдырды.

Компаниягә нигез салучы Татьяна Владимировна Бакальчук бүген залда утыра. Татьяна Владимировна, Сезгә хезмәттәшлегебез өчен зур рәхмәтемне җиткерәм.

Товар сату базарын киңәйтү өчен тагын бер мөмкинлек – ул контейнерлы товар ташуны арттыру. Республиканың Транспорт министрлыгына һәм Сәнәгать министрлыгына базарның төп катнашучыларын җәлеп итү һәм тиешле инфраструктура булдыру өчен комплекслы чаралар күрергә кирәк.

Хөрмәтле депутатлар!

Агросәнәгать комплексы республика икътисадының иң әһәмиятле тармакларының берсе булып тора.

Быел без бөртекле культуралардан яхшы уңыш җыеп алдык, ул 5 млн тоннадан артыграк булды. Тулаем алганда, 1,8 млн тонна шикәр чөгендере, үсемлек мае җитештерә торган культуралар – 600 мең тонна, бәрәңге – 800 мең тонна, яшелчәләр 260 мең тонна җыеп алыныр дип көтәбез.

Татарстан азык-төлек продуктларының төп төрләре белән тулысынча тәэмин ителгән һәм ул республикадан читтәге төбәкләргә дә шактый зур күләмдә продуктлар чыгара ала. Авыл уңганнарына авыр, әмма гаять мөһим хезмәтләре өчен бик зур рәхмәт!

«Татнефть» компаниясенә һәм аның генераль директоры Наил Өлфәт улы Мәгановка тармакны ел саен сыйфатлы ягулык белән ташламалы шартларда тәэмин итүе өчен аеруча зур рәхмәт сүзләремне җиткерәсем килә.

Безнең авыл хезмәтчәннәре алдында ирешелгән күрсәткечләрне югалтмау һәм авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүне арттыру юнәлешендә җитди бурычлар тора. Болар туфракның уңдырышлыгын яхшырту, шулай ук сугару комплексын үстерү исәбенә башкарылырга мөмкин.

Республика – терлекчелек төбәге. Мөгезле эре терлекнең баш саны ягыннан без илдә беренчеләр сафында.

Шуның белән бергә, кайбер муниципалитетларда фермалар ябыла һәм терлекләрнең баш санының бик күпкә кимүе күзәтелә.

Район башлыкларын инвесторлар белән бергәләп эш урыннарын саклап калуны, мөгезле эре терлекнең баш санын агымдагы ел башындагы план күрсәткечләре дәрәҗәсенә җиткерүне тәэмин итүләрен сорыйм.

Терлекчелек продукциясе җитештерү ягыннан алдынгы урыныбызны ышанычлы төстә саклау мөһим: сөт җитештерү буенча – 2 млн тонна, ит җитештерү буенча 550 мең тонна күрсәткеченә ирешергә бурычлыбыз.

> Хезмәт алдынгыларыбызга ихлас йөрәктән рәхмәт сүзләремне җиткерәм. Кукмара районы уңганнары тарихта беренче буларак тәүлегенә тулаем алганда 400 тонна сөт савып алуга иреште. Әтнә, Балтач, Саба районнарында тәүлегенә 300 тоннадан артык сөт савып алына. Моның нәтиҗәсендә исә республикада сөт җитештерүдә бик югары мөмкинлекләргә ия булган нәсел бирергә сәләтле терлекләр көтүе булдырылды.

Тулаем алганда, терлекчелектә заманча технологияләр кулланып фермаларны яңартып кору, терлек азыгы үзәкләрен төзү эшен дәвам иттерергә кирәк. Бүгенге көндә 18 муниципалитетта шундый 35 үзәк эшли башлады.

Терлек азыгы үзәкләре һәр районда булырга тиеш. Алар агрофирмаларны һәм шәхси хуҗалыкларны сыйфатлы терлек азыгы белән тәэмин итә. Бу эш Кукмара, Саба, Әтнә, Мамадыш, Балтач, Теләче һәм Тәтеш районнарында тиешенчә алып барыла.

Авыл хуҗалыгы тармагында алынган чималны эшкәртү системасын җайга салу таләп ителә. Бу өлкәдә сөт эшкәртүгә бәйле уңышлы мисал бар: әле 5 ел элек кенә республика предприятиеләре төбәктә савып алына торган сөтнең нибары 50 процентын эшкәртсәләр, бүген бу күрсәткеч 91 процентны тәшкил итә.

Хуҗалык алып баруның кече формаларына ярдәм итү өчен без ел саен 2 млрд сум бүлеп бирәбез. Моңа 20гә якын төрле чаралар керә. Халык белән эшләүне аеруча системага салып оештырган районнар исәбенә Балтач районы керә, монда һәр гаилә диярлек сыер асрый, Әтнә, Чүпрәле, Спас районнарында исә һәр икенче гаиләдә сыер асрала.

Без киләчәктә дә авыл хуҗалыгы предприятиеләребезгә, фермерларыбызга, шәхси хуҗалыкларга ярдәм күрсәтүне дәвам иттерәчәкбез.

Бүген без бу залга республиканың авыл хуҗалыгы өлкәсен үстерүгә зур өлеш кертүче фермерларны чакырдык: Тукай районыннан Ренат Ханов, Аксубай районыннан Ильяс Сөләйманов, Менделеевскидан Рәис Әгъләев, Балтач районыннан Азат Дәүләтшин, Лаештан Елена Нигъмәтҗанова, Чүпрәле районыннан Альфред Хәйруллин. Бик зур рәхмәт! Уңышлар сезгә!

Республика шәһәрләрендә ел саен авыл хуҗалыгы ярминкәләре оештырыла. Авыл халкы безгә кулай бәядән сыйфатлы продукция алып килә. Моның өчен шәһәрдә яшәүчеләр исеменнән зур рәхмәтемне белдерәм. Бу эшне дәвам иттерергә кирәк.

Бакчачылык һәм яшелчәчелек эше аерым социаль әһәмияткә ия. Миллионнан артык татарстанлы үзләренең бакчаларында һәм йорт янындагы җир кишәрлекләрендә эшли һәм ял итә. Гражданнар өчен бу – ял гына түгел, бәлки үзләрен экологик яктан зарарсыз азык-төлек белән тәэмин итү мөмкинлеге дә.

2017 елдан без бакчачылык ширкәтләренә ярдәм күрсәтәбез. Моңа 3,5 млрд сум бүлеп бирелде һәм бу акча бакчачылык ширкәтләрен су, электр энергиясе белән тәэмин итү, юллар салу һәм чүп чыгару өчен тотылды. Киләсе елда бу программаларны үтәү дәвам иттереләчәк.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

IT-өлкәне үстерүгә аерым тукталып үтәргә телим.

Татарстанда игълан ителгән Цифрлаштыру елында зур эш башкарылды. Ел ахырына кадәр республика гражданнарына барлык 325 дәүләт һәм муниципаль хезмәттән электрон рәвештә файдалану мөмкинлеге тудырылачак.

Төп тармакларны цифрлаштыру эше дәвам иттереләчәк: мәгариф өлкәсендә «Мин – укучы» – укучының цифрлы ярдәмчесе сервисы эшли, сәламәтлек саклау өлкәсендә – Республика клиник хастаханәсе базасында Россиядә беренче буларак халыкара стандартларга туры китереп медицина ярдәме күрсәтү тәртибе цифрлы нигезгә корылачак, торак-коммуналь хезмәтләрне цифрлаштыру өчен бер платформада гражданнарны, урта һәм кече бизнесны һәм идарәче компанияләрне берләштерәчәк яңа «Локоло» сервисы гамәлгә куелды.

«Имин шәһәр» видеокүзәтүенең хокук саклау сегментлары үз нәтиҗәлелеген раслады. Ул җинаятьчелекнең кимүенә китерде һәм хокук тәртибен тәэмин итәргә мөмкинлек бирде.

Шулай ук югары тизлектәге интернетка тоташтыруны киңәйтү буенча актив эш алып баруны дәвам итәбез. Федераль программа кысасында 3,5 меңнән артык социаль объект югары тизлектәге интернет белән тәэмин ителде, элемтәнең югары тизлектәге каналларына беренче тапкыр 300дән артык авыл тоташтырылды.

Республиканың барлык социаль объектларын (бу исә 4,5 мең тирәсе объект) интернетка тоташтыру – якындагы елларда хәл итәргә тиешле бурычыбыз.

Моннан тыш, «Таттелеком» компаниясе быел авылдагы 100 меңнән артык хуҗалыкны зур тизлектәге интернет белән тәэмин итәргә ниятли.

«АК БАРС» банкка аеруча зур рәхмәт әйтәсем килә, аның ярдәме белән быел укытучыларга 24 мең ноутбук биреләчәк.

Республика башкаласында Бәшир Рәмиев исемендәге яңа технопарк ачу бу елның тагын бер мөһим проекты булачак. Монда югары технологияле компанияләр үсеше өчен шартлар тудырылган 50 мең кв. метрлык заманча мәйдан эшләячәк, анда 4 мең яңа эш урыны булдырылачак. Бу объект Татарстанда IT-индустрия үсешенә яңа этәргеч бирәчәк.

Шунысын да әйтеп китәргә кирәк, IT-инфраструктураны республиканың зур шәһәрләрендә булдыру белән генә чикләнмибез. Муниципаль IT-парклар Питрәч, Саба, Мамадыш районнарында ачылды. Бу эшне дәвам иттерәчәкбез.

Бүгенге көндә IT-өлкәдә критик мәгълүмати инфраструктураның куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен җитәрлек чаралар комплексын кабул итү ихтыяҗы туды.

Республика Хөкүмәтенә мониторинг чаралары һәм киберкуркынычка каршы көрәшүне оештыру өчен чаралар белән тәэмин итү, дәүләт секторын илдә җитештерелгән программа тәэминаты һәм җиһазларына күчерү эшен дәвам иттерергә кирәк.

Хөрмәтле депутатлар!

Кешеләр турында кайгырту – элеккечә үк безнең игътибар үзәгендә.

Без тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән илкүләм проектларны һәм республика программаларын тулы күләмдә үтәүне дәвам иттерәбез. Быел аларның саны 44кә җитә. Татарстан бюджетыннан 46 млрд сумнан артык акча бүлеп бирелде.

3,5 меңнән артык социаль-мәдәни өлкә объектларын төзү, яңартып кору, төзекләндерү, капиталь төзекләндерү эше алып барыла. Болар – яңа һәм заманча мәктәпләр һәм балалар бакчалары, ресурс үзәкләре һәм тулай тораклар, фельдшер-акушерлык пунктлары, стационарлар, мәдәният йортлары һәм яшүсмерләр клублары, спорт мәйданчыклары һәм чаңгы базалары, балаларны савыктыру лагерьлары һәм күп кенә башка объектлар.

Барлык программа һәм проектларны гамәлгә ашыруда аларның үзара килештерелгән булуын тәэмин итү төп әһәмияткә ия. Бу эшкә комплекслы карарга кирәк. Торак төзү белән генә чикләнмичә, социаль, транспорт, инженерлык, бизнес инфраструктурасы объектларын төзүгә, шулай ук территорияне тулаем төзекләндерүгә игътибар бирү шарт. Моның өчен шул исәптән яңа төзелгән Киңлекләрне планлаштыру институты һәм Киңлек мәгълүматлары фонды җаваплы.

Моннан тыш, программаларны гамәлгә ашырганда, беренче чиратта, гражданнарның ихтыяҗларын истә тотарга кирәк. Бу исә хакимиятнең һәм җәмгыятьнең яшәү һәм эшләү өчен уңайлы тирәлек булдырырга омтылышларын берләштерергә мөмкинлек бирәчәк.

Айдар МЕТШИН,
Россия Дәүләт Думасы депутаты:

– Без авыр чакта һәрвакыт берләшә белдек. Хәзер дә шундый вакыт. Минемчә, без бу чорны уңышлы узачакбыз. Тотрыклылык һәм үсешкә басым ясалды. Президентыбыз Юлламасында республиканың нәтиҗәле үсеше өчен нигез булып торган төп юнәлешләр билгеләнде. Болар – суверен, нәтиҗәле икътисад, милли кыйммәтләр, икътисадтагы барлык тармакларның үсеше. Минемчә, җәмгыятьнең берләшүе – Юлламада яңгыраган төп фикерләрнең берсе. Хәзер һәр гамәл берләшеп башкарылырга тиеш. Республика Россия субъектлары арасында күп кенә тармаклар буенча алдынгы санала. Минем шигем юк: Президент атаган нәтиҗәле икътисад нигезен тәшкил иткән төп кыйммәтләр безгә алга таба үсештә булырга ярдәм итәчәк.

Айрат ФӘРРАХОВ,
Россия Дәүләт Думасы депутаты:

– Президент еллык Юлламасында бик мөһим мәсьәләләргә игътибар итте. Беренчедән, Президентыбыз программаларны халык белән килештереп кабул итәргә кирәклеген искәртте. Бу урында ул «Безнең ишегалды» программасын телгә алды. Халык тарафыннан тәкъдим ителгән программа бу. Аның ни дәрәҗәдә уңышлы эшләвен күреп торабыз. Президентның Юлламасыннан соң сәләтле балалар белән эшләүгә игътибарны арттырырга кирәклеге дә аңлашыла. Алар – безнең киләчәгебез. Медицина хезмәткәрләренең фидакарь хезмәтен билгеләп үтүе дә ошады. Коронавирус инфекциясе барыбыз өчен дә җитди сынау булды бит. Президентыбыз гаиләләрне саклау проблемасына да игътибар итте. Бу мәсьәләгә федераль закон чыгаручылар да кушылырга тиеш. Бүген парлар дистанцион рәвештә генә дә аерылыша ала. Бу дөрес түгел. Ул эшне катлауландырып, гаиләне саклап калу юлларын эзләргә кирәк.

Марат ҖӘББАРОВ,
Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры:

– Президент Юлламасында авыл территорияләрен, терлекләрнең баш санын саклау мәсьәләсенә зур басым ясады. Тагын бер кат Татарстанда мөгезле эре терлекләрнең иң күп санда булуын әйтте. Эре һәм вак хуҗалыкларда 928 мең баш терлек бар. Терлек санын киметкән районнарга игътибар итеп, аларда баш саннарын кабат яңартырга кирәклеген әйтте. Без инде бу эшне алып барабыз, алга таба да шушы юнәлештә эшне дәвам итәчәкбез. Шәхси һәм фермер хуҗалыкларына ярдәм максатыннан, ел саен 2 млрд сум акча бүлеп бирелә. Киләсе елга финанслау сакланды. Программалар алга таба да сакланачак. Бу – авыллар өчен зур ярдәм. Гомумән, Президент күп тармакларга тукталды. Аларның барысы буенча да киләсе елларга программалар әзерлибез.

Сәрия САБУРСКАЯ,
Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил:

– Бүген Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Юлламадагы чыгышын өлешчә мобилизацияләнгән кешеләрне борчыган сораулар белән башлады. Илдәге вазгыятькә бәйле сораулар безгә тәүлек буе килеп тора. Үз якыннарын махсус операциягә җибәргән кешеләр турында бөтен ил белән кайгырабыз. Рөстәм Миңнеханов, өлешчә мобилизацияләнгән кешеләрнең гаиләләрен ялгыз калдырмаска, диде. Ул район хакимияте башлыкларына, оешма җитәкчеләренә ирләре өлешчә мобилизацияләнгән гаиләләрне аерым контрольгә алырга кушты. Алар ялгызлыкны сизмәсен өчен барысын да эшләргә кирәк. Бергә булганда гына җиңү яулый алабыз.

Тимур ХАЛИКОВ,
«Татарстан предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе» генераль директоры урынбасары:
– Бүген республика сәнәгате алдында зур бурыч тора. Безнең тупланган тәҗрибәләр, белемнәр яңа продукция җитештерү мөмкинлеген бирә. Алар чит илдән кертелгән товарларны да алыштырырга, эчке зур ихтыяҗларны канәгатьләндерергә тиеш.
Президент куйган бурычлар кирәкле юнәлештә баруыбызны аңлата. Чөнки сәнәгать предприятиеләре соңгы берничә айда башлаган эшләр иң төп стратегик бурычларга җавап бирә. Һәм алар барысы да республика үсеше өчен эшли. Юлламада без нәкъ шуны күрдек тә. Бөтен кеше дә гомуми максатларга эшләүне аңлый. Шуңа күрә безнең әлеге бурычларны үтәп чыгу мөмкинлегебез бар дип уйлыйм. Һәм әлеге партнерлыкның озак еллар дәвам итүен аңлыйбыз, – диде ул.

Рамил ТӨХВӘТУЛЛИН,
Татарстан Дәүләт Советы депутаты:
– Юлламада яңгыраган фикерләр, әлбәттә, күңелне сөендерде. Президентыбыз бөтен өлкәләргә кагылып китте. Быел ул чыгышын Татарстанның халык шагыйре Мөдәррис Әгъләмовның тел, милләтне саклауга багышланган шигыреннән башлады. Рөстәм Миңнехановның еллык Юлламасын нәкъ менә шушы мәсьәләгә басым ясап башлавы күңелгә май булып ятты. Киләсе елны Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан итү – үзебезнең милли, мәдәни, тарихи мирасыбызга игътибарны арттыру дигән сүз. Бу – безнең даими эшебез, билгеле. Театрлар эшләп килә, концертлар бара. Әмма Президент тарафыннан рәсми рәвештә игълан ителгәч, бу өлкәгә игътибар тагын да артачак дигән сүз. Без аңа бик мохтаҗ. Ник дигәндә, вазгыять катлаулы, киеренке. Шушы шартларда үз йөзебезне саклау мөһим. Без тел, мәдәният, милли мәгариф юнәлешләренең һәркайсына бик зур игътибар бирергә тиеш.

Ирина ВОЛЫНЕЦ,
Татарстанда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил:
– Юлламада хәзерге вакытта безгә берләшергә, бердәм булырга кирәклеге искәртелде. Ел нәтиҗәләре буенча республиканың иң төп тармаклар үсеше буенча алдынгы булуы сөендерә. Бу безгә икътисадыбызны үстерергә ярдәм итә. Эш урыннары булдырыла, ярдәмгә мохтаҗ булган кешеләргә игътибарны арттырырга ярдәм итә. Монда, беренче чиратта, күпбалалы, аз керемле гаиләләр, мөмкинлекләре чикле кешеләр, өлкәннәр күздә тотыла. Президентның илебезнең нигезе дип нәкъ менә традицион кыйммәтләрне билгеләве аеруча игътибарга лаек. Рөстәм Миңнеханов бу урында ныклы гаилә, өлкәннәргә хөрмәт, туган илгә мәхәббәт төшенчәләренең мөһимлеген ассызыклады. Юлламада киләсе елда Казанда яңа перинаталь үзәк ачылачагы да телгә алынды. Бу республикада аналар һәм балаларга да зур игътибар бирелүен күрсәтә.

Зилә ВӘЛИЕВА,
Татарстанның Иҗтимагый палатасы рәисе:
– Бүгенге юллама, җитәкчеләргә һәм депутатларга гына түгел, Татарстанда яшәгән һәрбер кешегә мөрәҗәгать булып яңгырады. Бу чарада Президент, иң элек, үз урыннарында яхшы нәтиҗәләргә ирешкән хезмәткәрләрне – укытучы, авыл хуҗалыгы эшчеләрен һәм башкаларны хөрмәтләде, безгә күрсәтте. Тулаем әйткәндә, Юлламаның төп асылы – халыкка һәм иҗтимагый оешмаларга мөрәҗәгать ул. Заманалар җиңел түгел. Хәзерге вакытта барыбызга да бердәм булырга кирәк. Бер-беребезне ишетү мөһим. Хөкүмәтме ул, халыкмы ул – кулга-кул тотынышып, куелган бурычларны үтәргә кала.

Моңа уңышлы мисал сыйфатында «Безнең ишегалды» республика программасын китерергә була. Ул һәркемне канәгатьләндереп кенә калмыйча, бәлки шатландыра торган нәтиҗәләргә нәкъ менә уртак тырышлык белән ирешергә мөмкин икәнен ачык раслады. Нәтиҗәдә 3 ел эчендә республикада меңнән артык ишегалды төзекләндерелде инде.

Ишегалларын карап тоту, аларда чисталык һәм тәртип саклау – районнарның турыдан-туры бурычы. Без җитәкчеләрдән һәм халыктан әлеге җирләргә сакчыл караш көтеп калабыз.

> Дәүләт хакимияте органнары алдында барлык планлаштырылган эшләрне тулы күләмдә башкарып чыгу бурычы тора. Шул ук вакытта катгый финанс-бюджет дисциплинасы, бюджеттан тотылган һәрбер сумның нәтиҗәле файдаланылуы тәэмин ителергә тиеш.

Торак-коммуналь хуҗалык тармагында халыкны борчый торган иң төп мәсьәлә – инженерлык челтәрләренең тузган булуы. Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе буенча федераль дәрәҗәдә Торак-коммуналь хуҗалыкны яңарту комплексы программасы әзерләнә. Шушы уңайдан гамәлдә булган коммуналь инфраструктурага җентекле инвентарьлаштыру уздырылырга, халыкта төзекләндерү эшләренең кайда һәм кайчан булачагы турында мәгълүмат булсын өчен, тәгаен объектлар, эш башкару сроклары һәм күләмнәре билгеләнергә тиеш.

Тулаем алганда, әлеге программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәсе күпфатирлы торак йортларны капиталь төзекләндерү программасы белән бер дәрәҗәдә булырга тиеш.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Республикада юл хуҗалыгы тармагында киң колачлы проектлар тормышка ашырыла. Бу – М12 трассасын төзү, шулай ук Мәскәүдән Екатеринбургка кадәр югары тизлекле трасса төзү кысасында Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узучы М7 трассасын реконструкцияләү.

Шулай ук Шәле – Баулы трассасы проекты кысасында Алексеевск – Әлмәт автомобиль юлын төзү эшләре алып барыла, ул М7 һәм М12 трассаларын М5 трассасы белән тоташтырачак һәм алга таба Казахстан белән Кытайга чыгу мөмкинлеге бирәчәк. Әлеге проектларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 2025 елда беренче категория юлларның озынлыгы ике тапкыр артачак, Идел һәм Кама елгалары аша ике күпер файдалануга тапшырылачак.

Болар белән берраттән, «Имин һәм сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысасындагы проектлар да тормышка ашырыла килә, шул исәптән Зур Казан боҗрасы, Вознесение тракты төзелә һәм Горький шоссесы реконструкцияләнә.

Проектларны гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәткәне өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенә олы рәхмәтемне белдерәм.

Моннан тыш, республика программалары кысаларында муниципаль юл челтәрләрен үстерү буенча эшләр дәвам итәлә. Һәр елны авыл территорияләрендә кимендә 700 мең километр юл төзелә һәм төзекләндерелә.

Казанда метроның икенче линиясе төзелә, ул пассажирлар агымы аеруча зур булган микрорайоннарны тоташтырачак.

Хөрмәтле депутатлар!

Бүгенге көндә эчке туризмны үстерү аеруча мөһим мәсьәлә булып тора. Моның өчен республикада бөтен мөмкинлекләр дә бар: тарихыбыз бай, мәдәни-тарихи объектларыбыз үзенчәлекле, табигатебез гүзәл.

Иң мөһиме – тиешле инфраструктура, шул исәптән туристлар өчен заманча җиһазландырылган, кыйммәт булмаган ял итү урыннары һәм кызыклы маршрутлар бар.

Тулаем алганда, шәһәр янын, табигатьтә ял итү урыннарын, экология туризмын үстерү, шулай ук «Соколка», «Зөя», «Кама Тамагы», «Лаеш», «Ак таулар», «Идел Болгарстаны» кебек туристлык кластерлары кысасында туристларны җәлеп итүнең яңа юнәлешләрен эшләү зарур. Моның өчен эшкуарларга туристлык объектларын эшләтеп җибәрүдә ярдәм күрсәтү аша әлеге эшкә бизнесны җәлеп итәргә, шулай ук федераль проектларда катнашырга кирәк. Шуны да билгеләп үтәм, без экосистемага зыян китермичә, кешеләргә табигатьтән файдалану өчен мөмкинлекләрне арттырырга тиеш!

Алда «Бөек Болгар юлы» төбәкара маршрутын үстерү һәм торгызу проекты кысасында зур күләмле эшләр тора. Әлеге мәсьәләдә без Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының ярдәменә ышанабыз.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Эшчәнлегебезнең тагын бер өстенлекле юнәлеше – мәгариф системасын үстерү. 2023 ел Россия Федерациясендә Укытучы һәм остаз елы дип игълан ителде. Илебез Президентының әлеге карары җәмгыятебездә укытучыларның һәм остазларның югары абруен, аларның хезмәте әһәмиятле булуын раслый.

Бүген без әлеге залга яраткан һөнәрләренә тугрылыклы һәм республикабыз үсешенә үз өлешен кертүче укытучыларны чакырдык. Алар арасында Казан шәһәренең 2 номерлы лицей-интернатыннан, 2022 елда Татарстан Республикасының Ел укытучысы исеменә лаек булган Илсур Рөстәм улы Җиһаншин, Лаеш районының Усад прогимназиясеннән, «Россиянең Ел укытучысы – 2022» бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының муниципаль этабы җиңүчесе Лариса Николаевна Ефимова, укытучылар гаилә династиясе вәкиле, нәселенең дүрт буыны буенча дәвам иткән укытучы һөнәрен сайлаган Рафикъ Нигъмәтҗан улы Закиров та бар.

Кадерле укытучыларыбыз, сезгә һәм барлык мөгаллимнәргә хезмәтегез өчен олы рәхмәтләребезне җиткерәм. Бик зур рәхмәт сезгә!

Үз эшенә чиксез тугры һәм югары һөнәри осталыкка ия булган бу шәхесләр – яшь укытучыларга гүзәл үрнәк. Мәгариф системасының төп бурычы – педагогик кадрларны тиешле дәрәҗәдә әзерләүне тәэмин итү. Югары уку йортларын тәмамлаучыларның иң белемлеләрен, иң яхшыларын укытучы һөнәрен сайларга кызыксындыру буенча эшне активрак дәвам итәргә кирәк.

Быелгы уку елыннан башлап һәр муниципалитетта педагогик юнәлешле сыйныфлар эшли башлады. Аларны тәмамлаучыларга әлеге юнәлештә максатчан укыту программасы буенча югары уку йортларына керүдә өстенлек биреләчәк.

Укучы һәм укытучыдан кала, белем бирү процессында ата-аналарның роле дә бик зур. Аларның мөмкинлекләрен тиешенчә бәяләргә кирәк.

Ата-аналарга балалар белән эшләү алымнарын өйрәтү максатларында «Адымнар» мәктәбендә «Ата-аналар университеты: «Мин – актив ата-ана!» дигән укыту-методик программа эшләнде. Әлеге программаны республиканың башка мәктәпләрендә дә файдаланырга кирәк.

Мәгариф өлкәсендә аеруча игътибар бирелә торган мәсьәлә – Татарстанда яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү. Әлеге максатларда күпмиллätле якшәмбе мәктәпләренә һәръяклы ярдәм күрсәтелә (әле күптән түгел генә республикада 25 бүлекчә эшләп килә иде, хәзер аларның саны 100гә җитте). Шулай ук милли мәгариф оешмалары челтәре үстерелә, аларда Россия Федерациясенең дәүләт теле – рус теле белән берраттән 7 туган тел: татар, чуаш, удмурт, мари, мордва, башкорт телләре һәм иврит өйрәнелә.

Файдалы һәм кирәкле җәмгать башлангычларына булышлык күрсәтүнең нәтиҗәле институты буларак, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе эшчәнлеген аерым билгеләп үтәсем килә. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе итеп үзгәртеп корып, аның функцияләрен киңәйтү турында карар кабул ителде.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы рус теле комиссиясе оештырылды. Татар теле буенча укыту-методик комплектлар һәм дәреслекләр, башка фәннәр буенча тәрҗемә басмалар эшләү эшендә шулай ук сизелерлек алга китеш бар.

Республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгына әлеге эшне алга таба да дәвам итәргә кирәк булачак.

Тел белеме бирүне өзлексез итү өчен мәктәпләр һәм югары уку йортларының үзара бәйләнешен җайга салу мөһим.

> Тагын бер бурыч – туган телләрне һәм мәдәниятне саклау һәм үстерүгә яшьләрне ныграк җәлеп итү. Бу эштә яңа технологияләр куллану һәм кайбер югары уку йортларындагы кебек фольклор-этнографик юнәлешкә басым ясау кирәк.

Мәгариф учреждениеләренең иминлеге халыкны борчый торган мәсьәләләрнең берсе булып кала. Күптән түгел генә Ижевск мәктәбендә булган фаҗига татарстанлыларның йөрәген әрнетте. Уку йортларын матди-техник яктан һәм сак хезмәтләре белән тәэмин итү буенча барлык тиешле йөкләмәләр бирелде. Муниципаль берәмлекләр башлыкларына әлеге мәсьәләне аерым контрольдә тоту зарур.

Хөрмәтле депутатлар!

Кадрлар – безнең төп байлыгыбыз.

Сәламәтлек саклау системасы турында сүз алып барганда һәркемгә таныш булган әлеге сүзләрнең әһәмияте тагын да арта.

Гомерләрен хөрмәткә лаеклы, кешелекле һәм иң җаваплы һөнәрләрнең берсенә багышлап, медицина хезмәткәрләре игелекле бурычларын үти – кеше гомерләрен коткара, һәркем өчен иң кадерле нәрсә – сәламәтлекне саклап калырга ярдәм итә.

Бүген без шушы залга гомуми гаилә стажы 100 елдан артып киткән медицина өлкәсе династияләрен чакырдык. Бу – Вахитовлар, Ибраһимовлар, Минабетдиновлар, Лодвиковлар, Савельевлар гаилә династияләре. Хөрмәтле медиклар! Сезгә һәм барлык медицина хезмәткәрләренә тырыш хезмәтегез, тирән белемегез, үз һөнәрегезгә тугры булуыгыз өчен олы рәхмәтемне белдерәм.

Медицина хезмәткәрләре пандемия чорында кыюлык һәм фидакарьлек белән эшләделәр, бик күп татарстанлыларның гомерен һәм сәламәтлеген саклап калдылар.

Йогышлы чир белән авырган кешеләрне терНәкләндерү максатларында Казан шәһәренең 7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе базасында зур дәвалау-терНәкләндерү үзәге ачылды.

Бүгенге көндә Россиядә коронавирус белән бәйле кертелгән барлык чикләүләр дә бетерелде диярлек. Ләкин шулай да гражданнарга үз сәламәтлекләренә җитди карарга һәм шәхси саклану чараларын кулланырга киңәш ителә.

Аналарның сәламәтлеге һәм сәламәт бала тудыру – сәламәтлек саклау өлкәсендә элеккечә мөһим мәсьәләләрнең берсе булып кала. Киләсе елда 7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсенең балалар тудыру йорты базасында ачылачак заманча перинаталь үзәк – әлеге юнәлештәге иң әһәмиятле проект.

Хроник чирләре булган авыруларга диспансер тикшерүләре уздыруны оештыру мәсьәләләре аерым игътибар бирүне таләп итә. Җирле үзидарә органнары профилактик тикшерүләр уздыруда медицина оешмаларына тиешле ярдәмне күрсәтергә тиеш.

> Тулаем алганда, сәламәтлек саклау культурасы күнекмәләрен формалаштыруга этәргеч бирүче профилактик тикшерү чараларына басым ясау гаять мөһим. Республикадагы зур үсештә булган спорт инфраструктурасы, шулай ук спорт чаралары уздыру да моңа булышлык итәчәк.

Быел Татарстан спортчылары безне һәм илебез халкын 4 олимпия медале белән шатландырды, шулай ук тарихта беренче тапкыр уздырыла торган «Дуслык уеннары»нда һәм Бөтенроссия спартакиадасында республикабыз исеменнән лаеклы чыгыш ясап, волейбол, су полосы һәм чирәмдә хоккей буенча (ир-ат һәм хатын-кызлар җыелма командалары) 19 алтын медаль яулады.

Чирәмдә хоккей буенча 20 нче тапкыр чемпион исеменә лаек булган Татарстанның «Динамо – Ак барс» ир-ат командасының уенчылары барлык рекордларны узып китте. Шулай ук чирәмдә хоккей буенча хатын-кызлар командасы да Россия чемпионатында җиңү яулады.

Без үзебезнең спортчы-чемпионнарыбызны бүген әлеге залга чакырдык. Алар: Зөлфәт Гәрәев, Полина Мухорчева, Александра Фомина, Евгения Косецкая, Сергей Сирант һәм Александр Красных. Без сезнең уңышларыгыз белән горурланабыз һәм яңадан-яңа җиңүләр көтеп калабыз!

Спорт өлкәсендә генә түгел, ә мәгариф, фән өлкәсендә, сәнгатьтә казанышларга ирешкән яшьләребез шулай ук зур ихтирамга лаек. Россиядә һәм халыкара мәйданда уздырылган иҗат конкурслары лауреаты Инсаф Ганибаев һәм Казанның 131 номерлы лицеен тәмамлаган, математика буенча халыкара олимпиадада җиңүче Галия Шәрәфетдинова, Казанның 19 номерлы гимназиясе укучысы, мәктәп укучыларының икътисад буенча бөтенроссия олимпиадасы җиңүчесе Әмир Салихов, КФТТУ студенты, теоретик механика буенча халыкара интернет-олимпиадасында призлы урын яулаган Юрий Мельник, шулай ук Татарстанның беренче «КАИ-1» Җир ияречене уйлап табучылар һәм Россия Президенты грантына ия булган яшь галимнәребез нәкъ менә шундыйлардан.

Сезгә алга таба да зур уңышлар телибез! Сез – безнең киләчәгебез!

Сәләтле балалар һәм яшьләр белән эшләүнең нәтиҗәле системасын формалаштыру – илебез Президенты тарафыннан билгеләнгән төп юнәлешләрнең берсе. Безнең бурыч – яшьләр киләчәктә тормыш итү һәм үсеш урыны буларак Татарстанны сайласын өчен аларга уку, эшләү һәм ял итү өчен барлык шартларны булдыру.

Агымдагы елда федераль дәрәҗәдә балалар һәм яшүсмерләрнең гомумроссия дәүләт-иҗтимагый хәрәкәтен оештыру турында игълан ителде, аның күзәтчелек советын Владимир Владимирович Путин җитәкли. Әлеге хәрәкәт яшь буынны берләштереп, нигезен Ватанга мәхәббәт тәшкил иткән һәм көчле Россия төзү кебек уртак максатка ирешүгә юнәлдерелгән тәрбия бирүнең яңа алымнарын формалаштыруга хезмәт итәчәк.

Әлеге бурычларның гомумдәүләт дәрәҗәсендә әһәмиятен исәпкә алып, республика Хөкүмәтенә Татарстанда яңа хәрәкәтне оештыруда һәрьяклы ярдәм күрсәтүне йөклим.

Безнең төп бурычларның берсе – мәдәни мирасны саклау, өйрәнү һәм арттыру.

Татарстанда «Яңарыш» фонды эшчәнлеге һәм Беренче Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев ярдәмендә мирасны саклау өчен күп эш башкарылды. Минтимер Шәрип улына һәм бу мөһим эшкә өлеш кертүчеләргә, шул исәптән мәдәният хезмәткәрләренә чын күңелдән рәхмәтемне белдерәм.

Безнең мәдәният эшлеклеләренең хезмәте федераль дәрәҗәдә шулай югары бәяләнүе гаять куанычлы. Быел Алабуга музей-тыюлыгы генераль директоры Гөлзадә Рәкыйп кызы Руденкога Россия Федерациясенең Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә дәүләт премиясе бирелде.

Тарихи-мәдәни мирасны саклау һәм арттыру, иҗади башлангычларга ярдәм итү – гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү өчен мөһим бурычлар. Республикада мәдәният учреждениеләрен яңартып кору эшләре дәвам итә. Әлеге объектларның заманча җиһазландырылган булуы, үзләренең иҗади сәләтләрен ачу һәм үстерү өчен төрле буын вәкилләре һәм төрле һөнәр ияләре аларга теләп йөрүе бик мөһим.

Чаллы шәһәрендәге «Мастеровые» рус драма театры һәм быел «Мәдәният» илкүләм проекты кысасында Зеленодольск һәм Алабуга шәһәрләре мәдәни мирас үзәкләре моның ачык мисалы булып тора. Алар әлеге шәһәрдә яшәүчеләрнең яратып килә торган ял итү урынына әйләнде.

Киләсе елда Шиһабетдин Мәрҗанинең, Федор Шаляпинның һәм Максим Горькийның юбилейлары билгеләп үтеләчәк. Әлеге түгәрәк даталар бөек ватандашларыбыз иҗаты аша халкыбызның бай рухи дөньясын ачу мөмкинлеге бирә.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Һичшиксез, республикабыз ирешкән уңышлар һәм казанышлар – барлык татарстанлыларның, хакимиятнең барлык тармаклары һәм дәрәҗәләренең уртак хезмәте нәтиҗәсе. Уртак эшкә безнең депутатларыбыз да үзләреннән саллы өлеш кертә. Фәрит Хәйрулла улы җитәкчелегендә депутатлар корпусына Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә игелекле хезмәтләре өчен олы рәхмәтемне җиткерәм. Бик зур рәхмәт сезгә!

Хөрмәтле депутатлар!

Кадерле ватандашлар!

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Без, күпмилләтле Россия, Татарстан халкы, гасырлар дәвамында буыннан буынга тапшырыла торган гореф-гадәтләребез белән халкы рәвештә горурланабыз. Бу исә өлкәннәргә карата хөрмәтле һәм ихтирамлы мөнәсәбәт, хезмәт сөю, туган җиргә мәхәббәт, тату һәм нык гаилә төзергә омтылу традицияләре исән дигән сүз.

Әлеге асыл кыйммәтләрне без бүгенге көндә тагын да югарырак бәялибез. Алар безнең киләчәгебезнең һәм балаларыбыз киләчәгенең нигезен тәшкил итә. Шуларны өлге итеп яшәсәк, без барлык авырлыкларны да җиңеп чыгачакбыз.

Алдыбызда төрле өлкәләрдә җитди бурычлар тора. Уртак тырышлык белән без аларны үтәп чыга алачакбыз.

Без бергә!

Без булдырабыз!

kremlin.ru

> Атышлар дәвам итә, кешеләр үлә. Неонацистлар тормыш тәэмин итү объектларына диверсияләрнең террорлык ысулларын ачыктан-ачык куллана, хакимият органнары вәкилләренә һөҗүм итә, безнең территорияләргә диверсия төркемнәре юллый. Украина махсус хезмәтләре Кырым күперендәге шартлауны да оештырды. Россиянең башка төбәкләрендә дә, шул исәптән кеше күпләп җыела торган урыннарда да, теракт очраклары булдырылмый калынды. Шул исәптән атом-төш энергетикасы объектларында да.

Иминлек хакына

Киев режимы сөйләшүләрдән баш тартты, террорчы ысулларыннан файдаланып, Россиянең яңа территорияләрен утка тота. Россиянең Куркынычсызлык советы утырышында Президент Владимир Путин шулай дип белдерде. Моннан тыш ул ил составына яңа кушылган дүрт төбәгендә (Луганск һәм Донецк халык республикалары, Херсон һәм Запорожье өлкәләрендә) хәрби хәл режимы кертелүе турында игълан итте. Дөрес, әлеге территорияләрдә бу режим гамәлдә иде инде. Хәзер барысын да Россия законнарына туры китерергә генә кирәк. «ВТ» шушы утырышта яңгыраган төп фикерләрне тәкъдим итә.

Төбәкләрдәге режим

Россия Президенты Луганск һәм Донецк халык республикалары, Херсон һәм Запорожье өлкәләрендә хәрби хәл режимын игълан итү турында указга кул куюын белдерде. Режим 20 октябрьдән гамәлгә керде. Әлеге хокукый режим гражданнарга һәм хәрбиләр өчен нәрсә эшләргә кирәклеген төгәл билгели. Херсон, Запорожье өлкәләре, Донецк һәм Луганск халык республикалары белән чиктәш субъектларда (Кырым, Краснодар крае, Белгород, Брянск, Воронеж, Курск, Ростов өлкәләрендә, Севастополь) «урта дәрәҗәдәге җавап» режимы игълан ителде. Бу территорияләрдә җәмәгать тәртибен, шулай ук хәрби, дәүләт һәм махсус мөһим объектларны саклау эше көчәйтеләчәк. Транспорт, элемтә һәм коммуникация объектларында «аерым режим» («особый режим») кертелә.

Үзәк федераль округның һәм Көньяк федераль округның башка төбәкләрдә «югары әзерлек дәрәҗәсе» кертелә. Россиянең үзәк һәм илнең көньягыннан кала, барлык төбәкләрендә (шул исәптән Татарстанда да) «база әзерлеге» режимы гамәлгә керә.

Россия Президенты төбәк башлыкларының хәрби нигезләмә кысасындагы вәкаләтләре турындагы указны имзалады. Аларга гаскәрләрнең ихтыяҗларын тәэмин итү һәм халыкны яклау, шулай ук ведомствоара координациягә органнары (территориаль оборона штаблары) булдыру бурычы куелган.

Урта һәм югары дәрәҗәдә әзерлек режимы кертелгән төбәк җитәкчеләре түбәндәге вәкаләтләрне тормышка ашырырга мөмкин:

– җәмәгать тәртибен саклауны көчәйтү;

– транспорт, элемтә һәм энергетика объектларында «аерым режим» кертү;

– халыкны имин саналган районнарга күчерү (вакытлыча);

– керү һәм чыгуга бәйле чикләүләр;

– транспорт чараларын тикшерү, аларның хәрәкәтен чикләү;

– критик инфраструктура объектлары эшчәнлеген күзәтү.

Координация советы

Ил хөкүмәте дә координация советы оештырачак. Аның җитәкчесе итеп Премьер-министр Михаил Мишустин билгеләнде. Әлеге советның максаты – махсус хәрби операция ихтыяҗларын тәэмин итү, шул исәптән хәрби, матди, медицина-санитар хезмәтләр техникасын тәзекләндерү һәм китерү, матди ихтыяҗны кайгырту, логистика эшен җайга салу.

– Без бүген хәрби хезмәт юлына баскан һәм Ватанны саклау бурычын үтәгән һәр кеше белән горурланабыз. Безнең барлык сугышчыларыбыз да, нинди бурычларны үтәсәләр дә, барлык кирәк-яраклар белән тәэмин ителергә тиеш, бу казарма җиһазларына һәм урнашу урыннарына, көнкүреш шартларына, экипировка һәм бүтән кирәк-яраклар, туклану һәм медицина ярдәмен күрсәтүгә дә кагыла. Килеп туган барлык мәсьәләләрне хәл итү өчен мөмкинлекләребез дә бар, – диде Владимир Путин бу җәһәттән.

Акчалата ярдәм

Владимир Путин хәрби хезмәткәрләргә ярдәм итү буенча да йөкләмә бирде. Мобилизацияләнүчеләргә дигән акча аена 195 мең сумнан да ким булмаска тиеш. Ил башлыгы кушуынча, Хөкүмәт әлеге максатларга бюджеттан 1 ноябрьгә кадәр акча бүлеп бирергә тиеш була.

Дәүләт башлыгы сүзләренчә, һәр кешенең куркынычсызлыгы барлык дәрәҗәдәге хакимият вәкилләренең проблемаларга ничек тиз җавап бирүенә дә бәйле.

– Без Россиянең куркынычсызлыгын һәм ышанычлы киләчәген тәэмин итү, кешеләрне яклау буенча бик катлаулы, масштаблы мәсьәләләрне чишү юнәлешендә эшлибез. Полигоннарда һәм уку үзәкләрендә әзерлек узучылар безнең ярдәмне тоярга, алар артында зур, бөек ил, бердәм халык булуын белергә тиеш. Кешеләр, предприятиеләр, хезмәт коллективлары белән даими элемтәдә торырга кирәк, – диде ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

24 октябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!»12+
09.00, 16.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «ФАРЦА». (Татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Татар халык җырлары» 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.30 «Татарлар» 12+
17.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Металлург» (Мг) – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
20.00, 21.00, 00.15 «Таяну ноктасы» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Соотечественники» 12+
01.05 «Ватандашлар» 12+
01.30 «Каравай». Соприкасаясь к миру прошлого 6+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Татар халык җырлары» 0+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Нурихан Фәттах турында телеочерк 6+
15.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
19.00, 22.05, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Большая премьера. Максим Матвеев. «ТРИГГЕР». Новые серии (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Андрей Смоляков, Александр Горбатов, Марина Александрова, Дарья Урсуляк, Сергей Газаров. «ХУДОЖНИК» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
23.00 «Бесогон ТВ» 16+
23.45 «Вечер» 12+
01.40 «Судьба человека» 12+
03.40 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Эктор Ломбард против Лоренцо Ханта. Трансляция из США 16+
07.00, 09.55, 12.55, 14.50 Новости.
07.05, 19.15, 21.25, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.00, 13.00, 03.50 Спец. репортаж 12+
10.20, 03.00 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
11.10 Матч! Парад 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 0+
13.50 «Громко». Прямой эфир
14.55 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Енисей» (Красноярск) – «Уфа». Прямая трансляция.
16.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Металлург» (Магнитогорск) – «Ак барс» (Казань). Прямая трансляция
19.25 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Локомотив» (Новосибирск). Прямая трансляция
22.05 Тотальный футбол 12+
22.35 «Один на один. Барселона – Бавария» 12+
22.55 Автоспорт. Российская Дрифт серия. Гран-при 2022. Трансляция из Сочи 0+
00.55 Регби. PARI Чемпионат России. «Стрела» (Казань) – «Красный Яр» (Красноярск) 0+
02.55 Новости 0+
04.05 «Владимир Юрзинов. Хоккей от первого лица». Док. фильм 12+
05.05 «Громко» 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» (S) 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Иван Колесников, Лукерья Ильяшенко, Виталий Кищенко. «ТВЕРСКАЯ» (S) 16+
22.10, 00.00 «БАЛАБОЛ» (S) 16+
02.20 «МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.30 «Давай разведёмся!» 16+
10.25 «Тест на отцовство» 16+
12.40 «Понять. Простить» 16+
13.40 «Порча». «Чёрный угол» 16+
14.15 «Знахарка» 16+
14.45 «Верну любимого» 16+
15.20 «ЛЮБОВЬ НЕ КАРТОШКА». 1-я – 4-я серии 16+
19.00 «ВЕРЬ СВОЕМУ МУЖУ» 16+
23.00 «Порча». «Экспресс-приворот». «Отвращение» 16+
00.05 «Знахарка» 16+
00.40 «Верну любимого» 16+
01.10 «Понять. Простить» 16+
02.00 «ВОСТОК-ЗАПАД» 16+
02.55 «Тест на отцовство» 16+
04.35 «Давай разведёмся!» 16+
05.25 «6 кадров» 16+
05.35 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «Герой 115». Док. фильм 16+
06.30 «24 октября – День подразделений специального назначения» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня. 16+
09.20, 23.25 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». «СОЛЕНЫЙ ВЕТЕР». 1-я серия 12+
10.45, 18.15 «Спец. репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.20, 15.05 «КРАПОВЫЙ БЕРЕТ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости. 16+
17.25 «Освобождение». Документальный фильм 16+
18.50 «Морские сражения». Док. сериал. «А. Маринеско: битва за «чистую» воду». Премьера! 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. «За фасадом стальной пары – Вера Мухина» 12+
22.55 «Между тем» 12+
00.40 «СЛЕДСТВИЕМ УСТАНОВЛЕНО» 12+
02.10 «В ДОБРЫЙ ЧАС!» 12+
03.45 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
03.55 «БЕЗ ПРАВИЛ». 1-я и 2-я серии 16+

25 октябрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ФАРЦА». (Татар телендә) 16+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – Казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 6+
21.00 «Соотечественники». «Я отзовусь... Фарид Яруллин» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». София Губайдуллина. Прикосновение к душе 12+
00.45 «Каравай». Мастер этно-художественного кадра 6+
01.15 «Татар әдәбияты дәресләре» 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+
05.35 «Татар халык җырлары» 0+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
15.30 «Ватандашлар» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 21.25 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
19.10, 22.10, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «ХОЛОДНАЯ ВОЙНА НИКИТЫ ХРУЩЕВА» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Большая премьера. «ТРИГГЕР». Новые серии (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Андрей Смоляков, Александр Горбатов, Марина Александрова, Дарья Урсуляк, Сергей Газаров, Кирилл Зайцев, Александр Устюгов, Виктор Добронравов, Андрей Мерзликин. «ХУДОЖНИК» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
03.00 Детективный телесериал «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55 Новости
07.05, 14.20, 15.00, 18.45, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00 Специальный репортаж 12+
10.25, 15.40, 03.00 Еврофутбол. Обзор 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20, 04.05 «Катар. Обратный отсчёт» 12+
16.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Авангард» (Омск) – «Барыс» (Астана). Прямая трансляция
19.30 Футбол. Лига чемпионов. «Зальцбург» (Австрия) – «Челси» (Англия). Прямая трансляция
21.45 Футбол. Лига чемпионов. «Бенфика» (Португалия) – «Ювентус» (Италия). Прямая трансляция
00.55 Футбол. Лига чемпионов. «Боруссия» (Дортмунд, Германия) – «Манчестер Сити» (Англия) 0+
02.55 Новости 0+
05.05 «Правила игры» 12+
05.30 «Наши иностранцы» 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» (S) 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ТВЕРСКАЯ» (S) 16+
22.10 Детективный сериал «БАЛАБОЛ» (S) 16+
00.00 «БАЛАБОЛ» (S) 16+
00.30 «Основано на реальных событиях» (S) 16+
02.15 Дмитрий Ульянов, Ольга Ломоносова. «ЗВЕРОБОЙ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.20 «Давай разведёмся!» 16+
10.20 «Тест на отцовство» 16+
12.30 «Понять. Простить» 16+
13.35 «Порча». «Царапины» 16+
14.10 «Знахарка» 16+
14.40 «Верну любимого» 16+
15.15 «ЛЮБОВЬ НЕ КАРТОШКА». 5-я – 8-я серии 16+
19.00 «НЕ ОТРЕКАЮТСЯ ЛЮБЯ» 16+
23.05 «Порча». «Тень луны». «Немой свидетель» 16+
00.10 «Знахарка» 16+
00.40 «Верну любимого» 16+
01.10 «Понять. Простить» 16+
02.00 «ВОСТОК – ЗАПАД» 16+
02.50 «Тест на отцовство» 16+
04.30 «Давай разведёмся!» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «БЕЗ ПРАВИЛ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.25 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». «СОЛЕНЫЙ ВЕТЕР». 2-я серия 12+
10.45, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «МАЙОР ВЕТРОВ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Морские сражения». Документальный сериал. «Григорий Щедрин. Огненная кругосветка». Премьера! 16+
19.40 «Улика из прошлого». «Огонь, вода и газовые трубы. Тайна взрывов «Северных потоков» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
00.35 «ИХ ЗНАЛИ ТОЛЬКО В ЛИЦО» 12+
02.05 «СЛЕДСТВИЕМ УСТАНОВЛЕНО» 12+
03.40 «МАЙОР ВЕТРОВ». 1-я и 2-я серии 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 24–30 ОКТЯБРЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)

Бу чорда очрашу-танышулар, һичшиксез, дәвамлы булыр. Романтик хисләргә дә урын калыр. Гомумән алганда, уңышлы, акчалы, файдалы, сөенечле һәм кызык атна.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)

Карьера баскычыннан менеп китү өчен бик уңайлы вакыт. Җитәкчегез алдында үзегезне күрсәтергә әзер булыгыз! Атна ахырында гаиләгезгә күңелле хәбәрләр килеп ирешүен көтегез.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)

Көч-куәтегез моңарчы күрелмәгәнчә, ташып торачак. Аны дөрес юнәлешкә борып җибәрәсе генә! Ләкин шуны истә тотыгыз: бу чорда килеп чыккан тынгысызлык, ризасызлыкның кайтавазы озак барырга мөмкин.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)

Шәхси тормышыгыз турында ачылып сөйли күрмәгез. Юкса хезмәттәшләрегез алдында абруегыз төшәргә мөмкин. Эш урынында үсү мөмкинлеге пәйда булырга торганда, һәрбер сүзне бик үлчәп сөйләргә кирәк.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)

Бумеранг кагыйдәсе шәп эшләячәк: ашка – аш, ташка – таш! Хафаланмагыз: күбрәк «аш»лы булачаксыз. Атна ахырында эштәге бер мәсьәләдә шикләнү, әчке курку хисе барлыкка килергә мөмкин.

КЫЗ (24.08 – 22.09)

Кәефегез шәптән түгелме? Ясалма рәвештә булса да күтәренкелек булдырырга тырышыгыз. Юкса кемнәрнедер сөендерәчәксез. Ял көннәрендә күңелегезгә сары май булып ятардай хәбәрләр ишетерсез.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)

Мөһим эшләрегезне менә хәзер тәмамлап куярга тырышыгыз. Кичектерсәгез, бик күп мәшәкать китерәчәк алар. Сөйкемле, тәмле телле булуыгыз хезмәт урынында кыен гына хәлдән җиңүче кебек чыгарга ярдәм итәр.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)

Атнаның беренче яртысында эшлекле бер тәкъдим ишетерсез. Аның турында кат-кат уйланулардан соң бик дөрес карарга килерсез. Керемнәрнең артуын көтегез.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)

Көнкүрештә борчыган проблемаларның очына чыгып сөенерсез. Матди хәлегезнең яхшыруына өмет-ышанычлар барлыкка килүен көтегез. Җитәкчегезгә чын сәләтегезне күрсәтергә җай чыгачак.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)

Тәвәккәллек, кыюлык кирәк хәзер. Тегеләй яки болай кагылсалар, сүз әйтүдән куркып калмагыз. Атна ахырында дустыгыз күңел кылларын тибрәтеп җибәрердәй яңалыклар җиткерер.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)

Тыйнаклыкны онытып, тирәгездәгеләргә үзегезнең көчле якларыгызны күрсәтегез әле. Барысы да таң калып, сезнең турында бөтенләй башкача уйлый башлаячак.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)

Планнарыгыз барып чыкмас, тырышулар файдасыз кебек тоелыр. Ләкин сез дөрес уйламыйсыз! Барысы да котелгәннән дә яхшырак килеп чыгар. Сабырсызланмаска, ашык-пошык карарга килеп ялгышмаска гына кирәк.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең гражданлык законнары бүлеге мөдире

ФӘТТАХОВ
Исрафил Имам улы

вакытсыз вафат булу сәбәпле, аның туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Ярдәмчел дустыбыз, гаиләсе өчен янып яшәгән хезмәттәшебезне югалту хәбәре тетрәндерде. Исрафил Имам улы турында якты хатирәләр безнең йөрәкләрдән җуелмас.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты коллективы, танылган әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, профессор, институтның 2001–2006 еллардагы директоры

ХИСАМОВ
Нурмөхәммәт Шаһвәли улы

вафат булу сәбәпле, аның балаларының һәм туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БИЛ БЕЛӘН БУТАМАСКА

Җир шарында яшәүчеләрнең 10 проценты хроник бөер авыруларыннан интегә. Үлем-китем очраклары буенча исә алар инфаркт, инсульт һәм шикәр чире авыруларыннан соң дүртенче урында тора. Соңгы елларда бөер авыруларының артып китүенә социаль челтәрләр дә зур өлеш кертте, дип саный белгечләр. Яшерен-батырын түгел, бүген анда үз сәхифәсен алып барган ике кешенең берсе – «табиб». Алар өйрәткәннәргә ышанып, үзлегеннән генә дәваланучылар да шактый. Бөерләр өчен бу нәрсәсе белән куркыныч? Бөер авыртуын бил авыртудан ничек аерырга?

Табиб-терапевт, нефролог, диетолог Регина АХУНЬЯНОВА шул сорауларыбызга ачыклык кертте.

:: Бөерләр ни сәбәпле борчый?

– Андый хәл еш кына пиелонефрит дип аталган бөер ялкынсынуы чире вакытында күзәтелә. Кеше аны еш кына гадәти ОРВИ кебек уздыра. Бу чир әнә шуның белән аеруча куркыныч. Шуңа кеше еш кына тиешенчә дәваланмый да. Бу исә чирнең тагын да азуына китерә. Бөердә таш булганда да кеше авыртудан интегә. Андый чакта бөерләр сызлап, чәнчеп авырта. Ташлар организмда тоз әйләнеше бозылганга күрә пәйда була.

:: Ир-ат белән хатын-кыздагы бөер авыруы бер-берсеннән аерыламы?

– Зифа буйлы, ябык, корсак тирәсендә май катламы аз булган хатын-кызларның бөерләре еш кына арка ягыннан түгел, ә нәкъ менә корсак тирәсеннән авырта. Шуңа күрә гүзәл зат бөере авыртканын белми дә, эчем авырта дип зарлана. Бөерләрне салкын тычкан бизгәге вакытында да кешенең эче авырта. Бөерендә хилафлыклар булган ир-атлар исә, гадәттә, бил авыртудан зарлана.

:: Сүз уңаеннан, бөер авыртуны бил авыртудан ничек аерырга?

– Хроник бөер авырулары булган кеше бу очракта эшнең нидә икәнен шундук аңлап алачак. Бөерләр борчыганда, авырту билдән өстәрәк, арка ягыннан сизелә. Бил авыртканда, кеше билдән астарак өлештә уңайсызлык сизә, кеше хәрәкәтләнгән саен, авыру да көчәеп йөри. Бөер исә бер урында гына борчып тора.

:: Бөерләр авырткан мәлдә хәлеңне ничек җиңеләйтергә мөмкин?

– Андый чакта күпләп су эчәргә, авырткан урынны җылытырга кирәк, дигән фикер яши. Бу – зур хата. Бөерләр ялкынсынган вакытта аларны бигрәк тә җылытырга ярамый. Бу авыртуны көчәйтәчәк кенә. Бөерләр борчыган мәлдә авыртуны баса торган дару эчеп куярга кирәк. Аннары кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итеп, гомуми кан анализы тапшырырга, бөер һәм сидек капчыгына УЗИ ясатырга кирәк. Кешенең 38–39 градуска кадәр температурасы күтәрелсә, йөзе, бармаклары шешенә башласа да, кичекмәстән табибка күренергә кирәк. Бөерләр сәгатенә 50–70 мл бәвел фильтрлый. Шуңа күрә кеше көн дәвамында кече йомыш белән азрак йөри башласа, тәнлә исә, кисренчә, ике-өч тапкыр бәдрәф юлын таптаса да, бөерләрне тикшертергә кирәк.

:: Бөер авыртудан интеккән кеше ничек тукланырга тиеш?

– Бөерендә таш булган кешеләргә организмдагы тоз әйләнешен җайга салырга кирәк. Моның өчен шоколад, кофе, тозлы, ысланган, сөт ризыкларын чикләргә кирәк. Бөердә хилафлык булганда аксымны да чама белән генә ашарга кирәк. Андый кешеләргә аксымлы диеталарда утыру, БАДлар, зур дозадагы витаминнар эчү тыела. Бүген күп кенә «Инстаграм» «табиб»лары, шул ук блогерлар күп күләмдә (5000 берәмлектән артык) Д витамины эчәргә киңәш итә. Бу бөернең кальций белән агулануына китерә. Ягъни бөер күзәнәкләренә кальций утыра. Ул исә әлеге мөһим органның эшчәнлеген боза. Соңгы арада бу хәл хәтта балаларда да күзәтелә башлады. Моңа әти-әниләрнең баласын һаман да шул социаль челтәрләрдә язылганнарга нигезләнеп, үзлегеннән генә дәваларга маташуы сәбәпче.

vk.com

БӨЕРЛӘР СӘЛАМӘТ БУЛСЫН ӨЧЕН ТАБИБ КИҢӘШЛӘРЕ

1 Хроник циститны, җенси юл белән күчә торган авыруларны вакытында, ахыргача дәваларга кирәк.

2 Тамак авыртканда, стрептотест ясатып, сездә стрептококклы ангина түгелме икәнлеген ачыкларга кирәк. Ник дигәндә, стрептококк бактериясе бөерләргә ябырыла. Бу исә бөергә инфекция эләгеп, аның ялкынсынуына китерә. Соңгы арада гломерулонефрит диагнозы еш кына әнә шул ангинаны дөрес дәваламаган, аны аяк өсте генә уздырган кешеләргә куела.

3 ОРВИ, ковидны катлаулы формада уздырган кешеләргә дә авырып терелгәннән соң ике атна үткәч, гомуми кан анализы, УЗИ ярдәмендә бөерләрен тикшертергә кирәк. Гомумән, бу төр тикшеренүне елга бер мәртәбә һәркемгә узарга киңәш итәр идем.

4 Спорт белән шөгыльләнү дә бөер авыруларын кисәтергә ярдәм итә. БАДлар, аксым диеталар, протеинлы батончик, система ярдәмендә ала торган витаминнар белән мавыгучыларга да сак булырга кирәк.

5 Морс, сок, компот кебек баллы суларны гади суга алыштыру хәерле. Организмда тоз әйләнеше бозылган кешеләргә минераль су эчәргә дә киңәш ителә.

Шифасы булсын!

САЛКЫН ТИГӘНДӘ

→ **Бал һәм лимон белән җылы чәй.** Әгәр сезгә салкын тигән икән, беренче эш итеп, кара яки яшел чәй ясагыз. Аңа 1 чәй кашыгы бал һәм берничә телем лимон салыгыз. Файдалы матдәләрен саклап калу өчен, бал һәм лимонны кайнар суга салырга кирәкми.

→ **Юкә чәчәкләре белән кура җиләге чәе.** Юкәнең кипкән чәчәкләреннән чәй кайнатыгыз, аңа кипкән җиләк һәм кура җиләге яфраклары өстәгез һәм 30 минут тотыгыз. Әгәр кура җиләге юк икән, аның кайнатмасын да кулланырга була.

→ **Гөлҗимештән чәй.** Беркемгә дә сер түгел, гөлҗимеш – С витамины чыганагы. Вакланган гөлҗимешнең кипкән җимешләрен (3 аш кашыгы) 0,5 л кайнар суга салып, төнгә термоста калдырыгыз. Ашарга 30 минут кала көненә 4 тапкыр ярты стакан эчегез.

→ **Сарымсак белән сөт.** Бу эчемлек сезгә бер төн эчендә аякка басарга ярдәм итәчәк. Җылы сөткә 10 тамчы сарымсак суы салырга һәм төнгә каршы эчәргә кирәк.

→ **Лимонлы имбир чәе.** Салкын көннәрдә иммунитетны ныгытачак һәм эшкә сәләтлелекне арттырачак. 1 стакан кайнар суга 1 аш кашыгы бал, 1 аш кашыгы лимон суы, 0,5 чәй кашыгы вакланган имбир тамыры һәм бер чеметем дарчин салып болгатырга. Чәйгә бераз кипкән бөтнек яфракларын да салырга була.

→ **Минераль су белән кайнар сөт.** Әгәр сездә ютәл барлыкка килгән икән, минераль суга (Боржоми) кайнар сөт салып эчегез. Әлеге эчемлек какырык кубып чыгуга ярдәм итәчәк.

Тәмле дәва

ЮТӘЛДӘН КОКТЕЙЛЬ

Ярты банан, бер бал кашыгы какао порошогы һәм ярты стакан җылы сөтне блендерда болгатабыз. Блендер булмаса, бананны измә хасил булганчы изәбез һәм какао белән сөтне кушып туглыйбыз. Балага бу тәмле даруны җылы килеш эчерәбез.

Какао – теобромин чыганагы, ул тын юлларындагы спазмны ала, сулыш иркенәя. Сөт белән банан какырык кубаручы чара булып тора. Бу эчемлек нерв системасын да тынычландыра. Шулай булгач, бар яклап та файдалы.

Ишеттегезме?

СЕКС ИРТӘ КАРТАЙТА

Җенси активлык кешене иртә картайта, баш һәм арка миенең әкренләп кибүенә китерә. Калифорния галимнәре шундый нәтиҗәгә килгән. Алар уздырган тикшеренү нәтиҗәләреннән аңлашылганча, моңа канда җенси гормоннарның артык күп булуы сәбәпче икән. «Алар баш миенең нерв күзәнәкләренә тискәре йогынты ясый. Күселәр ярдәмендә ясалган тәҗрибә шуны күрсәтте», – ди галимнәр.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

САНАП САКЛЫЙБЫЗ

Һәркемнең үз гомерендә бер генә тапкыр булса да экономия режимына күчәргә мәҗбүр булганы бардыр. Бәяләрнең үсүе, көтелмәгән чыгымнар, кыйммәтле әйбер өчен акча туплау, кризис галәмәтләре билне кысыбрак буарга мәҗбүр итәргә мөмкин. Акча санаганны ярата. Аны дөрес тоту буенча түбәндәге киңәшләр файдага булыр.

Исәп һәм хисап

Чыгымнарны алдан санап, дөрес тәртип белән алып барганда, бурычка керү куркынычы янамый. Керем һәм чыгымнарны телефонда махсус кушымталарда яки дәфтәргә язып бару яхшы. Керем дигән бүлеккә хезмәт хакы, премия, пособие, пенсия, башка керем чыганакларын сумнарда язып чыгыгыз. Аннан соң әлеге акчаны торак өчен түләү, юлда йөрү, уку, туклану, кием һәм башка кирәк-яраклар өчен бүлеп чыгарга була. Чыгымнарның беренче һәм икенче чираттагыларга аерабыз. Мәсәлән, торак өчен түләми калырга ярамый, ә чәч кистерү, яңа кием алу кебек чыгымнарны кичектереп торырга да була.

Азык-төлек кибетендә

Тиз генә азык-төлек кибетенә кереп чыкканнан соң, өйгә кайткач, пакетта ашау өчен кирәкле бер юньле әйбер дә булмавы ачыклана. Хәйран гына суммада акча тотып, «буш» кайткан вакытлар да булгалый. Монда бәяләрнең үсүе, сатучы да гаепле түгел. «Кердем, күрдем, алдым», – дип сатып алу акча янчыгын бик тиз чистарта. Акча экономиялим дип, ашауны кысарга түгел, ә азык-төлек кибетенә барганда беренче чиратта кирәк булган әйберләрне алу максаты белән килергә кирәк. Тозга дип барып, тоз алмый кайткан чаклар да булгалый бит. Суыткычны тикшергәннән соң кирәкле әйберләр исемлеген язып чыгу файдалы. Әлбәттә, ризыкны ялларда зуррак кибетләргә яки базарга чыгып, атналык итеп алганда акчаны янга калдыруыгызны сизәрсез. Ташламага кызыгып әйбер алу да һәрвакыт отышлы булмый. Күп очракта яраклылык вакыты чыккан ризыкларны да ташламалы бәядән сатарга мөмкиннәр. Шуңа чекларыгызны ашамлык кибетендә калдырып кайтмагыз, сыйфатсыз ризык эләккәндә, аны кире кайтару өчен кирәге чыгуы бар.

Кием алганда янга калдыру

Кием һәм аяк киеме кибетенә төгәл нәрсә кирәген белмәгәндә кермәвең хәерле. Матур киемнәр күреп баш әйләнгәндә, кирәкмәгән әйбер алып кайтуыгыз бар. Экономияләү максатыннан килгәндә, киемнәрне яңа коллекциядән түгел, ә ташлама булганнарын сайлагыз. Ә сез ошатып калган киемгә күпмедер вакыттан шулай ук ташлама булырга мөкин бит. Яңа гына модага кергән кием алганда шуны онытмагыз: бер сезонннан аның модасы чыгачак. Шуңа күрә классик стильгә өстенлек бирсәгез, алдатмассыз, аны әллә ничә сезон рәхәтләнеп киеп була. Ә мөнә аяк киеменә акча жәлләргә кирәкми, чөнки очсызлы аяк киеме озакка җитмәячәк. Әгәр аяк киеменең уңайлылыгына шикләнсәгез, башта өйдә генә йөреп карагыз. Уңайлы булмаса, аның акчасын кире кайтара аласыз. Ә кибеткә чыгар алдыннан танышларыгыздан ташлама ясый торган карталар алып торсагыз да була.

Бакчачыга

Соңламаска

Бакчада бүгеннән дә калмый башкарырга кирәкле эшләр турында исегезгә төшерәбез.

✓ Җимеш бирә торган агачларның кәүсәләрен һәм скелет ботакларын корыган кабыклардан, мүк һәм лишайниклардан чистартыгыз һәм 5 процентлы тимер купоросы эремәсе бөркегез.
✓ Җиләк куаклары (кура, карлыган, крыжовник) антракноз яки тутык авыруы белән зарарланган булса, 3 процентлы бордо сыекчасы эремәсе яки бакыр купоросы эремәсе белән эшкәртергә кирәк.
✓ Кура җиләгенең ике янәшә куактагы ботакларын, өшүдән саклау өчен, берберсенә каршы саклык белән генә җиргә мөмкин кадәр якынрак бөгәргә һәм бәйләп куярга кирәк. Шулай ук бер куакның ботакларын икенче куакның төбенә бәйли-бәйли барырга мөмкин.

Фарсил ЗЫЯТДИНОВ киңәшләре

Үзем сынадым

АРАХИС ЙОМШАК ЯРАТА

Кибеттә чистартылган арахис алган идем. Кызык өчен генә, бер конкурста катнашып карыйм әле дип, февральдә дымлы чүпрәккә төреп бүрттердем һәм аерым стаканнарга 1әр см тирәнлеккә чәчтем. Бик тиз, яхшы тишелеп чыктылар. Арахисның яфраклары да матур икән. Бер өлешен балалар бакчасына алып бардым, икенче өлеше өебездә тәрәзә төбендә үсеп утырды. Июнь урталарында, кыраулар куркынычы беткәч, бакчага күчердем. Арахисның чәчәкләре кызгылт-сары төстә, вак кына, сырганак сыман сабагына ябышып тора.

Чәчәгеннән чыккан мыекларын туфрак белән өеп куярга кирәк, җир астында шул чәчәгеннән өстәмә тамыр китеп, шул тамырда чикләвекләр ярала. Туфрак гел йомшак булырга тиеш. Моны берничә тапкыр эшләсәгез, чикләвекләре күбрәк була.

Утыртканнан соң 40 көн узгач, уңышны җыйдык. 10 төптән бер куш уч чистартылган чикләвек чыкты. Киләсе елга тагын да күбрәк утыртырга уйлап торам.

Гөлүсә ГАЛӘВЕТДИНОВА. Чистай

Белеп тор!

КӘЕФ КҮТӘРҮ ЫСУЛЛАРЫ

Кара күзгә кергәндә кәеф төшү – гадәти хәл. Тик аннан арыну өчен түбәндәгеләрне башкару да җитә.

1 Кәефегез төшә башласа, активлыкны арттырыгыз. Моның өчен урамда саф һавада йөрү, йөгерү, фитнес һәм башкалар ярдәмгә килер.
2 Өегезне, сумкагызны яки телефоныгызны чистартыгыз.
3 Үзегез яраткан ризык белән сыйланыгыз. Баллы булса да ярый.
4 Күңел күтәрү көне ясагыз: дус яки туганнарыгыз белән очрашыгыз, матурлык салонына барып килегез яки табигатьтә йөрегез.
5 Күңелегезгә хуш килә торган кешегез белән театр, кинога барыгыз.
6 Ванна яки мунча керегез.

Исеңдә тот!

Яраннарны яңартабыз

Җәй буе өйне һәм бакчаны бизәп утырган яраннар киләсе язда тагын шаулап чәчәк атсын дисәгез, аларны кисәргә кирәк. Кискәннән соң аның йоклаган бөреләре уяна, ботаклары ишәеп, матурланып китә.

▸ Ноябрь урталарына кадәр аны кисү өчен уңай вакыт, ә менә декабрьдә яран йокыга китә, шуңа да кагылмавың яхшы.
▸ Бакчадан алып кергән яранны шундук кисмәгез. Моны 1–2 атна ияләшкәннән соң башкару яхшы.
▸ Яранны кискәндә үткен пычак сайлагыз, үтмәс пычак аны зарарларга мөмкин.
▸ Кисканче, ике көн су сипмәскә киңәш ителә.
▸ Зарарсызландыру өчен, кискән урынга вакланган күмер яки көл сибәргә кирәк.
▸ Көз өлгермәсән, яранны февраль ахырларында кисәргә мөмкин.

Файдалы

ЯШЬЛЕК ЭЛИКСИРЫ

Иммунитетны күтәрә торган катнашманы ясау өчен 50 мл җитен мае, 3 лимон, уртача зурлыкта ике баш сарымсак, 150 г бал кирәк булачак.

Чистартылган сарымсак һәм лимонны кабыгы белән иттарткычтан чыгарып, җитен мае һәм бал белән яхшылап болгатырга. Суыткычта бер атна тотарга. Аннары көненә 3 тапкыр ашар алдыннан бер чәй кашыгы кабарга кирәк. Әлеге катнашманы бер ай кулланып, өч ай тәнәфес ясагач, кабат кулланырга була.

ҖӘҺӘННӘМ УТЫН ДА СҮНДЕРӘ

Шатлыктан да, кайгыдан да түгәргә туры килә. Күз яше дигәнең адәм баласын әнә шулай гомер буе озата бара. Соңгы арада бигрәк тә юлдаш булды ул безгә. Мөселман кешесе өчен елау – ни дәрәҗәдә күркәм гамәл? «Хатын-кызның күз яше җиргә төшмәс» дигән гыйбарә каян чыккан?

«Мәрҗани» мәчете имам-хатыйбы Ансар хәзрәт МИФТЯХОВ белән шул сорауларга җавап эзлибез.

:: Ислам дине елау, күз яше түгүгә нинди мөнәсәбәттә?

– Күз яше – Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән нигъмәт, адәм баласы күңеленең йомшаклыгын билгели торган кичереш. Күз яше төрле була. Кеше борчукайгы килгәндә дә, шатланганда да күз яше түгә. Мөэмин мөселман кешенең иң шатлыклы яше – адәм баласының күзеннән Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт йөзеннән чыккан яшьләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Өч кеше иблистән һәм аның гаскәреннән котылачак: төнлә буена Аллаһыга зикер әйтүчеләр, төннең икенче яртысында Аллаһтан куркып елаучылар һәм кылган гөнаһлары өчен чын күңелдән тәүбә итүчеләр», – диелә. Шушы икенче төркемгә керүчеләр турында сүз йөрткәндә, төннең икенче яртысында тәһәҗҗуд намазында без Аллаһы Тәгаләдән кулыбызны күтәреп, елап сорыйбыз икән, ул, иншалла, безне Иблиснең кагылуыннан коткарачак. Аллаһы Тәгаләдән куркып түгелгән яшьнең бер тамчысы да җәһәннәм утын сүндерергә сәләтле.

Бервакыт пәйгамбәребезнең сәхабәләре Гайшә анабыз янына кереп: «Гайшә анабыз, сезгә бер соравыбыз бар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең иң күркәм гамәлләре турында әйтегез әле», – дигәннәр. Гайшә, елап, болай ди:

– Бервакыт ул төнлә намаз укырга торды һәм миңа: «Гайшә, мине ялгызымны гына калдыр әле гыйбадәт кылырга», – диде. Мин: «Аллаһ белән ант итәм, мин синең янәшәңдә булырга яратам. Сине бәхетле кылган гамәлләр мине дә шатландыра», – дидем. Ул, тәһарәт алып, намаз укырга җыена башлады. Гадәттә, намаз укыганда аның тезләре, хәтта тирәсендәге җир дә дымлана иде.

Шул вакытта азан әйтмәкче булып, Билал керде һәм пәйгамбәрнең күз яшьләрен күреп: «Син ник елыйсың, Аллаһы синең булган һәм булачак гөнаһларыңны кичерде бит», – диде. Ул: «Мин рәхмәтле кол булырга тиеш түгелме? Бу төндә миңа берничә аять иңдерелде. Кем дә кем намаздагы аятьләрнең мәгънәсен белмичә укый икән, шуның хәле бик тә аяныч», – дип әйтте.

Безгә Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышы үрнәк булып торырга тиеш. Кызганыч, хәзерге заманда күпләребез аның елый-елый намаз укыганын истә тотмый, бик азларыбыз ихластан гыйбадәт кыла.

:: Хатын-кызның күз яше җиргә төшмәс, Аллаһы Тәгалә хатын-кызның күз яшен санар, дигән гыйбарә яши халыкта. Мөселманнарда хатын-кызның елау, күз яше түгүенә ни өчен шулкадәр зур игътибар бирелә икән?

– Язид Рәкаши пәйгамбәр галәйһиссәләмнән риваять итә. Ул анда: «Берәү балалар өчен базардан ашамлык күтәрсә, хәтта ашамлыкны авызларына салганга чаклы сәдака биргән нәрсәне күтәргән кебек булыр. Ул кеше ашамлык биргәндә кызлардан бирә башласын. Чөнки Аллаһы Тәгалә хатын-кыз өчен мәрхәмәтле. Бер кеше хатын-кызларга йомшарса, Аллаһыдан куркып елаган кеше кебек булыр. Бер кеше Аллаһыдан куркудан

еласа, аның гөнаһы ярлыканыр. Бер кеше кыз балага шатланса, Аллаһы Тәгалә ул кешене көенеч көнендә шатландырыр», – дигән. Исламда хатын-кызның елау, күз яше түгүенә ни өчен шулкадәр зур урын бирелүе әнә шуннан бик яхшы аңлашыла.

:: Өшкергәндә күз яше агу нәрсәне аңлата?

– Әгәр өшкергәндә өшкерүче кешенең күз яше ага, ялса ул авыз ача икән, аңа ярдәм сорап килгән кешегә күз тигән яки анда бозым булырга мөмкин. Мондый бәндәне ешрак өшкертергә кирәк. Өчҗиде тапкыр өшкерелсә, тагын да яхшы.

:: Якын кешең үлгәч, еламаска, яшь түкмәскә кушалар. Мәет су эчендә ятар, диләр. Ул ни өчен шулай әйтелә?

Татарстан халыкны бәрәңге белән – тулысынча, ә калган яшелчәләр белән 65 процент тәэмин итә. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы китергән мәгълүматлар буенча, быел республикада бәрәңге һәм башка төр яшелчәләр 7,1 мең гектар мәйданда чәчелгән. Бу – узган ел белән чагыштырганда 12 процентка артыграк дигән сүз. 800 мең тонна бәрәңге, 260 мең тонна яшелчә җыеп алырга планлаштыралар. Аларның 65–70 мең тоннасы эре һәм фермер хуҗалыкларында үстерелә. Әйтик, узган ел барлык хуҗалыклар да 200 мең тонна яшелчә җыеп алганнар иде. Гомумән алганда, республика халкына елына 330 мең тонна яшелчә кирәк.

Чыннан да, узган ел ахырында министрлык яшелчәчелек белән шөгыльләнүче хуҗалыкларга субсидияләр вәгъдә итте. Яз-җәй айларында яшелчә үстерүче барлык җитештерүчеләр гектарына 25 мең сум ярдәм алса, игү мәйданнарын узган ел белән чагыштырганда 10 һәм аннан да күбрәк процентка арттырган хуҗалыклар һәр гектарга 40 мең сум күләмендә субсидия алды. Моның өчен бюджеттан 81,6 млн сум акча бүлеп бирелде.

Субсидия алучылар арасында Кукмара районының Зур Сәрдек авылында яшәүче Хәмзә Хисмәтуллин да бар. Фермер соңгы елларда кишер, сарымсак һәм кәбестә үстерү белән шөгыльләнә. Шулай да соңгысына игътибарны күбрәк бирә. Быел ул 8 гектарга кәбестә утырткан. Уңышы да әйбәт буласы булган үзе, тик кинәт кенә авыру башланып, 80 проценты харап булган.

Бу тармакта тәҗрибәсе зур булган фермер әйтүенчә, яшелчәчелек базарында кәбестә бәясе – иң тотрыксызы. Бер елны ул 40 сумнан сатылса, икенче елга 4 сумга кадәр төшәргә мөмкин. Шуңа күрә узган ел уңышына кызыгып, быел кәбестә утыртучылар отар дигән ышаныч юк. Үстерүдә иң мәшәкатьлесе дә ул. Чөнки кул хезмәтен дә күп сорый, нәзберек тә. Киләчәктә иртә өлгерә торган сортлары тагын да кимүгә таба барыр, дип фаразлый белгеч.

Кәбестә бәясе төшүнең сәбәпләре, беренчедән, уңышның яхшы булуында булса, икенчедән, быел яшелчәчелек белән шөгыльләнергә теләүчеләрнең саны артуда.

– Беренчә ел рәттән кәбестәнең сату бәясе гел булмады. Ул хәтта чыгымнарны да капламады. Мондый хәл беренчә ел рәттән кабатлангач, күп кенә хуҗалыклар кәбестә утыртмый башлады, – дип аңлатты ул. – Бәрәңге белән дә шулай ук булды. Мәсәлән, бездә яхшы гына эшләп килгән «Вахит», «Урал» хуҗалыклары бу эштән китте. Нәтиҗәдә кәбестә үстерүчеләр кимеде һәм аның бәясе дә артты. Бәясе арткач, быел кызыгып утыртучылар кабаттан күбәйде. Министрлык та субсидия белән ярдәм итте. Һәм, билгеле, бәя төште. Бүген кәбестәнең килограммын 8–10 сумнан күпләп сатарга мөмкин. Августта 6 сумнан җибәрдек. Шуңа күрә моңа гаҗәпләнәсе юк: шулай буласы билгеле иде инде. Киләсе елга тагын кытлык булырга мөмкин. Башка яшелчәләргә кытлык быел да булмагае әле, чөнки көз яңгырлы булу сәбәпле, күп кешенең кишере җыелмаган. Әлегә кадәр бәрәңгесе кырда ятучы хуҗалыклар бар. Алга таба суыклар да вәгъдә итәләр.

Сүз уңаеннан, без шалтыратканда Хәмзә абый да кишер басуында иде: уңыш алу соңга калган. Тәҗрибәле фермер әйтүенчә, авырлык кәбестәне сатып булмауда түгел, ә аның бәясендә. Чөнки узган ел 40–50 сумга җибәргән яшелчәне быел 6–7 сумга сорыйлар. Ә фермерның андый бәягә сатасы килми. Ул уйлап торган арада, арзан бәягә дә риза булган күрше республика вәкилләре товарын бушатып та китә.

– Быел кәбестә утыртучылар «янды». Субсидия менә хәзер кирәк ул. Ашлык белән дә шулай булды бит. Уңышы мул, кереме начар булды. Ә яшелчәчелектә бу күптәннән шулай иде инде. Аңа игътибар гына бирелмәде, – диде фермер.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Газета укучылар игътибарына: Чистай районының Кызыл Ялан авылында Илгиз Сабиров хуҗалыгыннан кәбестәне килограммын 7 сумнан килеп җыярга мөмкин.

Фәния
ӘХМӘТҖАНОВА

КЫЗЛАР ДА КОШЛАР КЕБЕК

1941 елның октябрь аенда СССР халык комиссариаты боерыгы нигезендә составында бары тик хатын-кызлар гына булган беренче Тамань авиация полкы төзелә.

«Дунькин полк»

Оештыру эшләре белән очучы Марина Раскова җитәкчелек итә. Полк командиры итеп ун еллык очучылык стажы булган Евдокия Бердянская билгеләнә. Аның җитәкчелегендә кызлар сугышның соңгы көннәренә кадәр фашистларга каршы көрәшә. Кайчакларда полкны, шаяртып, «Дуня полкы» («Дунькин полк») дип тә йөртәләр. Полкны формалаштыру, өйрәтү эшләре Энгельс шәһәрендә үткәрелә. Әйтергә кирәк, шушы боерык нигезендә аңа кадәр дә хатын-кызларның ике полкы оештырылган була. Әмма соңракниндидер сәбәпләр белән ул катнашка әйләнеп китә. Ә «Дуня полкы» исеменә дә, җисеменә дә хилафлык китерми.

1942 елның 23 маенда полк фронтка оча. 27 майда килеп җитә. Ул вакытта аның составында 17дән алып 22 яшькә кадәрге 115 кеше була. Полк 218 нче төнге бомбардировщиклар авиациясе дивизиясе составына керә. Кылган батырлыклары өчен 23 кызга Советлар Союзы исеме бирелә. 32 кеше һәлак була.

Мәгубә

Бу тарихи вакыйга безнең өчен бик истәлекле дә, кадерле дә. Әлеге полкта милләттәшебез, легендар очучы, Советлар Союзы Герое Мәгубә Сыртланова хезмәт итә. Аның кылган батырлыклары турында «Сугышчан дан клубы» республика ассоциациясе рәисе Михаил Черепанов сөйләде.

– Мәгубә Сыртланова – Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган бердәнбер татар кызы. Аның тиңдәшсез батырлыгы турында күпме генә язсак та, сөйләсәк тә, кино төшерсәк тә, аз булыр иде. Герой милләттәшебезне киләчәк буыннар да белергә, аның белән горурланырга тиешләр. Эскадрилья командиры урынбасары булып хезмәт иткән каһарман кызыбыз дошман гаскәрләрен юк итү өчен 780 очыш ясап, 190 тонна бомба ташлый. Кавказ, Тамань ярымутравы, Кырым, Көнчыгыш Пруссия һәм Берлин юнәлешендәге сугышларда катнаша. Нинди бәхет: бер тапкыр яраланып та карамыйча, дошманны үз өнендә тар-мар итә.

Безнең өчен тагын бер әһәмиятле мәгълүмат: кызлар очкан По-2 самолеты Казанда җитештерелгән. Димәк, алар күрсәткән батырлыкта Татарстанның өлеше зур дигән сүз бу. Очучы кызларны немецлар «төнге убырлар» дип атаганнар һәм алардан бик нык шүрләгәннәр. Бу очкычлар, тавышсыз гына, моторы сүнгән килеш, төгәл билгеләнгән урынны төнлә бомбага тота алганнар. Мондый самолетларны юкка чыгарган дошман гаскәрләренә зур бүләкләр вәгъдә иткәннәр. Кайчакларда кызларга бер төндә 8–9 очыш ясарга туры килә. Мәгубә Сыртланованың самолеты күп тапкырлар дошман утыннан качып котыла алган. 1944 елның апрель төнендә алар очкычына чираттагы тапкыр ут ачалар. Юк ителде дип исәпләп, дошман, күрәсең, экипажны ахыргача күзәтми. Җимерелгән очкычны кызлар читкәрәк алып китәргә

БЕЛЕШМӘ

Мәгубә Хөсәен кызы Сыртланова 1912 елның 15 июлендә Башкортстанның Бәләбәй шәһәрендә туа. Мәктәпне тәмамлагач, 1929 елда Ташкентта телеграфист булып эшли. Аннары граждланнар авиациясенең Урта Азия идарәсендә һава линияләре техникы вазыйфасын башкара. Тбилисида аэроклуб һәм Үзәк планерист мәктәбен тәмамлый. Сугыштан соң Грузиягә кайта, авыл хуҗалыгы авиациясендә эшли. Казанга килгәч, кияүгә чыга. Оборона заводларының берсендә ОТК контролеры булып эшли. 1971 елның 1 октябрендә Казанда вафат була. Татар зиратында җирләнгән. Аның исеме Казан һәм Бәләбәй шәһәрләренең урамнарына, Казанның 52 нче мәктәбенә, Бәләбәйнең 2 нче мәктәбенә бирелгән. Бәләбәйдә һәм Казанның 52 нче мәктәбендә Мәгубә Сыртланова музее эшли. Башкортстанның Благовещенск шәһәрендә, Краснодар краеның Актубә каласында, Казанда геройның бюсты куелган. Аның турында китаплар язылган, фильм төшерелгән.

tatfrontu.ru

Мәгубә Сыртланова укучылар белән очраша.

тырышалар. Бәхеткә, диңгез өстеннән яр буена китереп җиткерәләр. Очкычның башы – комда, койрыгы суда була. Бу Мәгубә өчен гомер буена онытылмаслык очыш булып истә кала. Соңгы тапкыр сугышчан бурычны ул 1945 елның 3 маенда үти.

Мәгълүматлардан күренгәнчә, Икенче Бөтендөнья сугышы вакытында сугышчан норма 25 очыш булган. Әгәр очучы шушы норманы үтәсә, ул бүләккә тәкъдим ителгән һәм сайлау хокукы бирелгән: хезмәт итүне син я җирдә дәвам итәсең, яки лаеклы ялга китәсең. Бу нормалар дөнья күләмендә гамәлдә булса да, безнең очучыларга кагылмаган. Кызыл армиядә башкача эшләгәннәр. Әгәр очучы 100 уңышлы очыш ясый икән, ул Советлар Союзы Герое исеменә лаек булырга мөмкин. Отставкага яки пенсиягә китү турында сүз дә булмаган.

Мәгубә Сыртланованы Советлар Союзы Герое исеменә, Ленин ордены һәм «Алтын йолдыз» медаленә бары тик 1946 елның 15 маенда гына лаек дип табалар. Ул тагын II дәрәҗә Ватан сугышы, ике тапкыр Кызыл Байрак ордены, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Сания

Татарстан Республикасында иң беренче очучы хатын-кыз – Казан аэроклубын тәмамлаган Сания Яруллина. Ул чордагы җирле газеталарда «Сания Яруллина СССРда иң беренче хатын-кыз – аэронавт» дигән сүзләр дә язылга. Дөрес, бу фикер соңрак бәхәскә тарый. Әмма ничек кенә булмасын, безнең республикада ул, чыннан да, беренче була.

Ул чорда СССРда авиация белән мавыгу мактаулга лаек була. 1920 нче елларда бөтен ил буйлап авиамодель түгәрәкләре эшли башлый. 1932 елда «Татосоавиахим»ның очучы-планеристлар станциясе ачыла, 1933 елда Казан аэроклубына нигез салына. Анда кызларны да, егетләрне дә кабул итәләр.

> 1934 ел башына 47 пилот һәм 200 планерист, 32 инструктор әзерләнә. Татарстанда беренче тапкыр самолеттан парашют белән сикерү 1934 елның 12 июнендә Казанда оештырыла. Очучы-планеристлар мәктәбендә әзерләнгән беренче инструкторлар үз чиратында 14 очучы-планеристлар түгәрәге һәм ике станция оештыралар.

1935 елның 11 гыйнварында танылклык алып чыккан очучылар арасында аңа кадәр пилот-планерист курсларын үткән Сания Яруллина да була. Ул аэростатта 3–4 сәгатьлек берничә очыш ясый. Казан аэроклубында күнекмәләрен дәвам итә.

Әле аэроклуб курсанты булганда ук ул үзенең дуслары белән Татарстанның барлык районнары буйлап «Кызыл Татарстан» дип аталган агиточышта башлап йөри. Аны «Красная Татария» газетасы редакциясе белән «Татосоавиахим» оештыра. Аэростатка колхоз бригадаларына өләшү өчен газеталар төялгән була.

Батыр очучының даны еракларга тарала. 1935 елда ук аны Ульяновскига, очучы-инструкторлар мәктәбенә укырга җибәрәләр. Ни кызганыч, Сания Яруллинаның шуннан соңгы язмышын ачыклап булмады. Интернет мәгълүматларыннан күренгәнчә, ул татар энциклопедиясенә дә кертелмәгән.

Сан

Бөек Ватан сугышы башланганчы «Татосоавиахим» Казан аэроклубы һәм аның филиаллары (Чистайда һәм КАИ каршында) **400** очучы, **120** очучы-инструктор, **240** планерист, **1500** парашютчы-спортчы, **116** авиамодельче әзерләп чыгара.

Тормыш үзгәрә

Әлбәттә инде, сугышка кадәр Сания беренче очучы булса да, бердәнбер булмый. Александра Парвицкая, мәсәлән, 1934 елда беренчеләрдән булып КАИны тәмамлый. Ул укыганда институтта аэроклуб эшли, студентларны У-2 самолетында очарга өйрәтәләр. Казан гражданнар авиациясе авиаотрядында сугышка кадәр Елена Милотина һәм Тамара Мелашвили оча. Вера Степанова белән Вера Тихомирова данлы сугыш юлы үтәләр. Күп кенә хатын-кызлар сугышта һәлак булган очучы ирләрен алыштыра. Әйтергә кирәк, 1930 нчы елларда Казанда 6 меңнән артык кыз очучы таныклыгы ала һәм аларның күбесе Бөек Ватан сугышында катнаша.

Бүген Россиядә 450 хатын-кызның зәңгәр күкне штурвал тотып иңләргә рөхсәте бар. Иң күбе – «Аэрофлот» компаниясендә, 20 хатын-кызның 5есе беренче пилот статусын йөртә. Бүген күп кенә аэрофлотлар хатын-кыз очучыларга нык игътибар итә, аларны эшкә алуны хуп күрә. Очучы хатын-кызлар саны буенча беренче урынны АКШ били. Монда бу һөнәр бик популяр санала. Дөнья авиакомпанияләре арасында хатын-кызларның өлеше – 10 процент чамасы. Әйтергә кирәк, бу сан арта бара. Россиядә дә үсү тенденциясе бар. Әмма бездә стереотиплар бик көчле әле. Кайвакыт, пилотның хатын-кыз икәнен белгәннән соң, авиабилетларын кире тапшыру очраклары да юк түгел. Хәер, бу хәл безгә генә түгел, Европа илләренә дә кагыла икән. Форсаттан чыгып, шуны да әйтергә кирәк: әлегә кадәр хатын-кызлар штурвал артында утырганда, бер генә фаҗига да теркәлмәгән. Күргәнебезчә, тормыш үзгәрә. Әле кайчан гына хатын-кызның машина руле тотуы да гаҗәп тоела иде бит.

Сәрия МИФТАХОВА

ЙОРТ ХАЙВАННАРЫ: КЕМГӘ – ЮАНЫЧ, КЕМГӘ – БӘЛА

Шәһәр фатирында эт-мәче, күгәрченнәр генә түгел, әтәч, елан, кырмыскаларга кадәр асраучылар бар. Берәүләр бу җанварларны күңелсез тормышларына бер ямь өстәү, икенчеләр кечкенә балаларын сөендерү, өченчеләр кызык өчен тота. Анысы – һәркемнең шәхси эше. Йорт хайваннары күршеләр белән татулыкны бозмыймы соң? «ВТ» хәбәрчесе хайван сөючеләрдән шул хакта белеште, Казанның Мусин урамындагы йортларның берсендә тугыз мәче асраучы Дания Ибраһимова белән дә очрашып кайтты. Сокланыргамы, әллә гыйбрәт алыргамы аннан?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кырмыска, елан...

Җан ияләрен бөтен кеше дә дустына әйләндерә алмый, моның өчен ярату кирәк. Әмма бу гына җитми, чисталыкны да сакламыйча булмый. Югыйсә күршеләрдән зар ишетеп торачаксың. Бу яктан Чаллы шәһәрендә яшәүче Иргалиевларның бер проблемасы да юк. Ник дигәндә, алар кырмыскалар асрый, бу бөҗәкләр чабышып йөрми, күршегә дә кермиләр.

– Улыбыз Радмирның кош-кортлар яратуын истә тотып, туган көненә дип биш ел элек әби-бабасы, туганнар әнә шундый ферма бүләк иткән иде. Хәзер аңа – 14 яшь, – ди әнисе Венера Иргалиева. – Кырмыскаларны тәрбияләү кыен түгел. Улыбыз «өй»ләрен юа, ашарга, эчәргә салып тора. Алар көнбагыш, ярма, үлән, вак бөҗәкләр белән туклана. Башта ферма бик аз урынны алып торса, хәзер кырмыскалар күбәйде, шуңа күрә ояларын зурайттык. Бу урын яхшы итеп ябылган. Кырмыскалар үзләре дә тәртип ярата. Чүпләрне бер урынга җыялар, йомырканы да аерым җиргә салалар.

Автокалада яшәүче Дания апа Дәүләтҗанова исә фатирында елан тота. Озынлыгы – 1,5 метрдан артык.

– Беләсезме, ул безгә ни чарадан бичара килеп эләкте. Елан – кызыбызныкы. Айгөл Мәскәүгә яшәргә киткәч алган иде аны. Ул вакытта нибары 18 сантиметр булса, хәзер озын инде. Кызыбыз өч ел элек Сахалинга командировкага китте, шунда безгә кайтарды. Ияләштек инде, – ди Дания ханым.

Хуҗабикә әйтүенчә, елан куркыныч түгел: кешегә тими, бумый. Ысылдамый, телен генә чыгара. Идәндә шуышып та йөргәли. Махсус пыяла савытта яши. Кунакка килүчеләр: «Юк, тотмыйбыз, суык, юеш бит ул», – диләр икән. Әмма бер тотып карагач, кулларыннан төшермиләр. Еланның тиресе йомшак, җылы. Әле узган төндә генә тиресен салган булган. Андый вакытта һәм ашаганнан соң гадәттә кулга алырга тырышмыйлар. Шәһәрдә еланны дәвалаучы мал табиблары юк, шуңа күрә киңәшләрне интернеттан табалар.

Ашарга күп кирәкми. Өч атнага бер мәртәбә дә тукландыру җитә. «Башта зоокибеттән туңдырылган тычкан ала идек. Хәзер катырылган чебиләр сатып алабыз. Өч атнага бер генә ашатабыз, 4 чеби йота», – ди Дания апа.

Әтәчегез кайда?

Әниләр бала хакына ниләр генә эшләми. Казанның Җиңү проспектындагы йортта яшәүче Альбина Ярмиева, улының теләген тормышка ашыру өчен, фатирында хәтта әтәч асраган. Дүрт яшьлек улының йомыркадан чеби чыкканын күрәсе килгән. Альбина эшләгән бакчага мини-зоопарк килгәч, хуҗасы аңа аурукан токымлы кошның зәңгәрсу йомыркаларын биргән. Менә шуннан әтәч чыккан да инде. Тиз арада балаларының дустына әйләнгән ул. «Серый» дигән кушамат та такканнар. Тик «кикрикүк» 2,5 яшьтә үлеп киткән. Хәзер дә бик сагыналар икән аны.

– Җиләккә барганда, һава сулар дип, әтәчне дә алган идек. Кайткач, җан тәслим кылды. Эссе сукты, ахры. Аны догалар укып күмдек, – дип сөйләде Альбина. – Бауга тагып, урамда йөрттек. Кешеләрдән бервакытта да начар сүз ишетмәдек. Сәгать биштә кычкырып уята иде. Берсендә безнең йортта яшәүчеләр «Ватсап»та: «Нинди әтәч кычкыра ул?» – дип яза. Мин әйтәм, кемдер эт, мәче тота, без исә балалар хакына дип әтәч алдык. Шуннан соң безнең хәлне аңладылар. Каты кычкырмасын өчен, операция ясатырга теләгән идек. Тик хирург алдан ук, үләчәк, дип кисәтте. Бугазына махсус җайланма бәйләгәч, тавышы басылды.

Акыллы булган бу әтәч. Альбина коймак пешергәндә янында көтеп торган. Хуҗабикә аны беренче булып сыйлаган. Эштән кайткач, хәтта башмакларына кадәр китереп биргән. Соң кайтса, үзенчә ачуланган. Томшыгы белән ишекне ачкан. Күңеленә ошамаганнарны чукырга да күп сорамаган. Күршеләре: «Кайда сезнең әтәч, ул булганда урамда күңелле иде», – дип юксына икән.

Мәчеләргә калган көн...

Казанның Мусин урамындагы бер йортта яшәүче инвалид Дания апа Ибраһимованы күпләр беләдер. Арбасын тартып, мәчеләренә чүплектән – икмәк, сөяк, кибетләрдән искергән башка продукция җыя ул. Аны, ник чүплек актарып йөрисең, дип сүгүчеләр дә, мәчеләрне ашаткан өчен рәхмәт әйтүчеләр дә бар. Элек ул урамдагы этләрне ашатып йөргән. Хәзер мәчеләренең тамагын кайгырта. Моны ул савап өчен эшли.

Әбинең яшәү шартларын, өендәге чисталык мәсьәләсен тикшерер өчен бармадык. Аның тормыш фәлсәфәсен, күршеләр белән мөнәсәбәтен беләсе килде. Кешеләргә ишек ачу гадәте дә юк икән. Волонтерларны да, башкасын да кертми. Әйберен урлап чыгып китәрләр, дип курка. Кешеләрдән туйдым, берсе дә кирәкми, ди. Кире борылырга дип торганда: «Татарча матур сөйләшкәнгә генә кертәм», – дип, ишеген ачты. Бусагада аркасына мәче кунаклаган бөкрәйгән карчык күренде. Югыйсә үзенә 70 кенә яшь. «Сез киләсен белсәм, чистартып куйган булыр идем», – дип уңайсызлангандай булды Дания апа. Үзе исә сасы исне сизми икән. Тараканы, кандаласы, чебене – барысы да бар. Әби шулай яшәргә күнеккән инде.

– Моңа кадәр 22 мәчем бар иде, хәзер аларның саны – 9. Күптән түгел берсе бала табып чыгып китте. Урамнан песиләр җыеп йөрмим. Үземнекеләр балалый. Ата мәчеләрне килеп алучылар да бар. Урамга чыгарып ата алмыйм, гөнаһы миңа булачак, – диде ул. Аннан авыр сулап сүзен дәвам итте. – Туганнарың үлеп бетсә, менә шушы җанварларны асрый башлыйсың икән ул. Алар минем белән бергә йоклый. Нәрсә әйткәнемне аңлыйлар. Миңа башка әйбер кирәкми. Гаиләдә өч бала идек, хәзер үзем генә калдым. Апамның ике баласын үстердем. Ирем Госман үлде, кызым ятимнәр йортында үсте. Мин түгел, каенана биргән. Кызым хәзер хәлемне белешеп тора. Мин бит – гарип. Детдомнан кайткач, I группа инвалидлык кенәгәсен алырга булышты. Аякларым авыртмый үзе, йөрмиләр генә. Хәзерге вакытта кияү янында яшим. Ул кызымның ире түгел, башка туганымныкы. Яшь чакта сәламәтлекне кайгыртмыйсың бит ул, мин дә берьюлы өч урында эшләдем. Башта – хисапчы, аннан урам себерүче... Хәзер инде шушы тормышымнан риза. Күршем юк, ул анда тормый. Гарип булгач, башкалар кызгана, сасы дип сүз әйтмиләр.

Бу җәһәттән икенче катта яшәүче Хәсән абый Сибгатуллин белән сөйләштек.

– Безгә кунакка килүчеләр, подъезддан ук, бигрәк сасы дип, борыннарын томалап керәләр. Чүплектән сөяк алып кайта да, шуны пешергәч, исе бөтен җиргә тарала. Күршеләр риза түгел инде. Әле аның тараканнары да бар бит. Әле бет тә бардыр, кем белә? Иске газ плитәсен чыгарган иде, анда миллион таракан күрдем. Пычраклыктан чыга бит алар. Аптырагач, берничә тапкыр өен чистартып карадылар, файдасы юк. Участковыйлар да бернишләтә алмый, закон юк, диләр. Дания үзе бик белемле, уен-көлке белән сөйләшә. Эчеп йөрми, – ди Хәсән абый.

«Бернишләтеп булмый»

Әлеге йортка җаваплы булган подрядчы оешмага да сугылдык. Анда мондый очраклар белән ничек көрәшәләр икән?

– Безнең районга тузган торак программасы буенча күчеп килүчеләр шактый. Хәзер һәркем фатиры өчен үзе җавап бирә. Халыкның 10–15 проценты – элек баракта яшәүчеләр. Менә шулар элеккеге гадәтләрдән арына алмый. Кемдер иске-москы җыя. Бер бабайның фатирына бөтенләй кереп булмый. Янгын-мазар чыкмагае дип куркып торабыз. Бер әби тизәген тәрәзәдән ыргыта. Авыру кешеләр инде алар. Күпләп эт, мәче, күгәрчен тотучылар да бар. Кайберләре бик чиста яши, кайбер фатирларда ул ис диварларга сеңгән. Әгәр фатирга таракан ияләшә икән, анда яшәүчеләр үзләре агуларга тиеш. Без бары чорма, подвалларны гына эшкәртәбез. Кисәтү ясыйбыз, тик бармак янап кына булмый бит. Алар коммуналь түләүне вакытында түләп бара. Хәзер андый кешеләргә социаль яклау бүлегеннән дә килеп йөрмиләр, бик кызганыч, әлбәттә. Үзләре исән вакытта туганнары күренми, үлгәннән соң күбесенең варислары табыла, – диде Казандагы 42 нче подрядчы оешма директоры Илсөяр Миндубаева.

Белгеч фикере

Гөлнара БЕГЛОВА, юрист:

– Россия законнары нигезендә, йорт хайваннары асраганда, хуҗаларына гомуми таләпләрне үтәргә кирәк. Административ хокук бозулар кодексында җанварларны тоту кагыйдәләрен бозуга бәйле махсус нормалар бар. Мәсәлән, Административ хокук бозулар кодексының 6.3 статьясында, халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге законнарны бозган өчен административ җаваплылык, ягъни гражданнарга 100–500 сум күләмендә штраф яисә кисәтү каралган. Кодексның 6.4 статьясы исә торак урыннарны, җәмәгать биналарын файдалануга карата санитар-эпидемиологик таләпләрне бозган өчен җаваплылыкны билгели. Бу – гражданнарга биш йөз сумнан бер мең сумга кадәр административ штраф.

Санитар нормаларны бозу, ис чыгу һәм тавыш булу сәбәпле, җәнлекләрне торак урыныннан чыгару турындагы дәгъваны канәгатьләндерү очраклары суд практикасында бар. Аерым очракларда, фатирны хайваннар өчен приютка әйләндергән милекчене, башка торак урыны бирмичә, фатирдан мәҗбүри рәвештә чыгарырга мөмкиннәр.

ИЛШАТ РӘХИМБАЙ:

«КИНОНЫҢ КУӘТЕН АҢЛАП ҖИТКЕРМИБЕЗ»

Татар киносы, аның проблемалары, режиссерлар, продюсерлар, сәерлек... Режиссер Илшат РӘХИМБАЙ белән без әнә шул хакта сөйләштек. «Гастарбайтер» фильмы режиссеры «Микулай»ның үзенчәлеге турында да сөйләде, «Кайчан караячакбыз?» дигән сорауга да ачыклык кертте.



«Татар-информ»

:: Илшат, Татарстандагы иң сәер режиссер кем?

– Миңа калса, дөньяда гомумән нормаль режиссер юк. Аларның барысы да сәер. Әгәр бөтенесен бергә җыйсаң, алар нормаль булып тоелырга мөмкин. Хәер, читтән күзәткән кешеләр режиссерны нормаль итеп кабул итә алмый, ул мөмкин хәл түгел. Шул ук вакытта, мин – иҗат кешесе бит әле дип, ясалма рәвештә сәерлек китереп чыгару, сәерлек артыннан куу – үзе бер гөнаһ, миңа калса. Ихласлыктан китү ул, киресенчә, иҗаттан ераклаштыра.

:: Ә синең сәерлегең нәрсәдә?

– Үземне сәер дип санамыйм. Адекват, нормаль кеше. Мин «нормальный», ә башкалар сәер. Сез минем нинди сәер кешеләр белән аралашканны хәтта күз алдына да китерә алмыйсыз! Әмма алар үзләре хакында киресенчә уйлыйлар. Монда кем хаклы икән? Масса артыннан иярү ул әле хакыйкатьне ачыклау дигән сүз түгел. Мәсәлән, кеше ашаучылар массасы булган, аларны хаклы дип әйтеп булмый бит.

:: Сүз уңаеннан, син – Кинематографистлар берлеге әгъзасымы? Гомумән, иҗат кешесенә берлекләр кирәкме?

– Мин Кинематографистлар берлегендә түгел әле. Башта алар чакырдылар, мин суза килдем. Аннары, икенче фильмны көтәбез дип, бу эшне кичектерергә булдылар. Дөресен әйткәндә, ул берлекләрнең нәрсәгә кирәклеген аңлап та бетермим, бәлки, үскәч аңлармын.

:: Юк, дияргә ашыкма әле. Миңа калса, берлекләр аша грантлар алып була, премияләр...

– Бәлки, чыннан да, ниндидер статус бирәдер. Мөгаен, грантлар алганда, дәүләт дәрәҗәсендә сөйләшүләр алып барганда ярдәме тиядер. Әмма яхшы фильм булган очракта, шул фильмнан да күбрәк ярдәм итә торган нинди исемлекләр була алганын мин аңламыйм. Яхшы идеяң, янып торган карашың, яхшы командаң, дусларың, планың булганда, әгъза катыргысы шулкадәр әһәмиятлеме?

:: «Алмачуар» проектыннан китүеңне, бүлеп бирелгән акчага риза булмаган, дип аңлаттылар. Чынлыкта да шулаймы?

– Бу проект, «Татаркино» турында сөйләшәсе килми. Чөнки һәрберебезнең – үз юлы, үз мөмкинлекләре, үз стратегиясе һәм үз кармасы. Андый оешмалар, берләшмәләр үз юлын үтә һәм берничек тә чагыштырып, алай булырга яки булмаска тиеш дип бәяләргә ярамый. Чөнки андый чагыштыру, акыл сату үзеңә кире әйләнеп кайта. Иң дөресе – үз юлыңны үтү.

:: Ә бармы соң ул татар киносы?

– Нәрсә соң ул татар киносы? Татарча төшерелгәнме, Татарстанда төшерелгәнме, татар кешесе катнашында төшерелгәнме яисә татар шәхесе, тарихы турында төшерелсә, татар киносы дип аталачакмы? Әгәр шушы билгеләмәнең берсе генә үтәлгән булса да, миңа калса, ул бар. Менә без Татарстанда керәшеннәр турында фильм төшердек. Ул рус телендә, әмма анда татарча уйналган сәхнәләр дә бар. Сезнеңчә, бу татар киносы дип саналамы? Минемчә, татар киносы. Чөнки аны мин төшердем, ә мин монда тудым, монда үстем һәм шушы җирдә белем алдым. Җыелган барлык көчемне һәм энергиямне шушы картинага салдым. Димәк, ул – безнең кино. Кемгә ничек атау уңайлы инде.

> Шәхсән мин киноның милләте юк дип саныйм. Кино ул – аудиовизуаль иҗат, аны берничек тә милләткә бәйләп булмый. Бу чынбарлыкта, бу дөньяда кешеләр белән аралашу, идеяләрне җиткерү өчен аерым бер тел ул. Аудиовизуаль тел. Анда татар телен дә, башка телләрне дә, рәсемнәрне, җырларны, төсләрне дә кулланып була. Кино ул – бик катлаулы матрица, аерым бер дөнья.

:: Синеңчә, иң яхшы татар фильмы кайсы?

– Минемчә, әле иң яхшы татар фильмы төшерелмәгән. Андый ачыш безне якын киләчәктә көтә, дип өметләник.

:: «Микулай» фильмы белән хәлләр ничек?

– «Микулай»ның хәлләре әйбәт. Ул инде әзерләнеп бетә, дияргә була. Мәскәү кинофестиваленнән соң кайбер фикерләрне язып алдык, шуларны искә алып, төзәтеп бетерәбез дә, ул әзер булачак. Дөрес, премьера 15 октябрьдә узды инде, Казандагы премьераны исә киләсе елга күчердек. Ул соңгы вакыйгаларга бәйле. Мөгаен, прокатны да киләсе елга чигереп торырбыз.

:: Әлеге пьесаны Мансур Гыйләҗев язган иде бит. Ул беткән авыл һәм ялгызлык турында иде. Ә фильм нәрсә турында?

– Кино – аерым бер дөнья дип әйткән идек бит әле. «Микулай» фильмында бу ачык чагыла инде. Пьесадан аермалы буларак, анда идеяләр күбрәк. Чөнки аудиовизуаль һәм башка мөмкинлекләр дә бар. Тамашачы исә үзен нәрсә борчый, нәкъ менә шул идеяне тотып алачак, миңа калса. Бу – фильмның байлыгы дип уйлыйм, чөнки без конкрет менә шушы тема турында гына уйланыгыз дигән бурыч куймыйбыз тамашачыга. Әлбәттә, анда кече халыклар проблемалары да, рәнҗетелгән халыклар борчулары да, кешенең үз-үзен гафу итә алмавы, аның трагедиясе, үз дөньяңа бикләнеп яшәү проблемалары да бар. Әмма конкрет бер кыса куелмый, һәр кеше үзенчә нәтиҗә ясый. Премьерадан соң, бу фильм уйландыра, аны берничә тапкыр карарга кирәк, шуннан соң ул тагын да ачыла, аңа тәм керә, дигән фикерләр яңгырады. Бу – бик зур бәя инде.

:: Татарстанда иң көчле режиссер дип кемне атар идең?

– Шушы юнәлештә даими эшләгән һәм коммерция юлыннан китмәгән кеше турында сүз барса, әлбәттә, Илдар Ягъфәров. Ул сайлаган юлыннан курыкмыйча бара, фильм артыннан фильм төшерә. Тел, татар темасын авырлыклардан, акчасызлыктан, тәнкыйтьтән курыкмыйча күтәрә, үз юлыннан тайпылмыйча бара. Ул – герой. Миләүшә Айтуганова исә чит төбәкләр белән элемтәләре барлый, ниндидер низаглар аша булса да, уртак проектлар булдыра. Кино ул – шундый индустрия инде, ул шулай барырга тиеш, юкса тукталып калу ихтималы бик зур. Һәм без аны аңлыйбыз. Татарстанның мөмкинлекләрен арттыру – бик зур эш һәм Миләүшә Айтуганова бу җәһәттән бик күп эшли. Бу өлкәдә чакырып торучы юк, алдыңда чемодан белән акча да ятмый, ишекләрне ачып, беркем дә көтеп тә тормый. Мин хәтта Татарстанда фильм төшергән бөтен кешене геройлар дип атыйм. Чөнки әле безнең кино фонды да юк, индустрия дә төзелмәгән. Шуңа күрә шушы идеяләр белән янган һәр кеше – каһарман.

:: Продюсерлар бармы бездә?

– Татарстанда продюсерлар аз, чөнки без бу юнәлешне аңлап бетермибез, аңа укымаган да, безне бу һөнәргә әзерләмәгәннәр дә. Продюсерларны дәүләт программасы булдырып әзерләргә кирәк. Бу – көн кадагындагы мәсьәлә. Әгәр кеше шушы юлда эшли, мәсәлән, кыска метражлы фильм төшереп карый, эзләнә, фестивальләрдә катнаша икән, ул, укытуны сорап, дәүләткә мөрәҗәгать итә ала. Гадәттә, дәүләтнең андый мөмкинлеге бар. Әлбәттә, укуын тәмамлагач, бирегә кайтып, фильмнар төшерергә сүз бирсә.

:: Җыеп әйткәндә, кинода төп проблема нәрсәдә?

– Төп проблема киноның нинди куәткә ия булуын аңлап бетермәвебездә. Шушы юлны сайлаган кешеләрнең дә эчләрендә курку утыра, миңа калса. Кино ярдәме белән кешеләрне үстерергә, матурлыкка китерергә, күңелләрне чистартырга, хәтта ниндидер психологик авырулардан терелтергә була. Шушы җаваплылыкны аңлаганда, төпле режиссерлар, продюсерлар барлыкка килер иде. Дәүләт белән бизнес бердәмлегендә бик матур проектлар туар иде. Бу инде индустриянең туууына һәм үсешенә китерер иде. Әлбәттә, проблемалар бик күп, алар комплекслы. Аларны күмәк уйлашканда гына хәл итеп була.

:: Иң соңгы укыган китабың?

– Джон Кехоның «Квантовый воин» китабы.

:: Яшең кырыкка җиткәндә, нинди фильм төшерер идең?

– Бәлки, 39 яшь турында төшерермен. Ул чакта, бәлки, аның турында нәрсәдер аңлармын. Ә менә 45 яшь җиткәндә нәрсәләр буласы турында 40 яшьтә, бәлки, төшерә алмам.

:: Әгәр ул картинага акча җитмәсә, гаилә бюджетын корбан итә алыр идеңме?

– Акча җиту-җитмәү ул – һәрвакыт авыр мәсьәлә. Фильмның берсе генә дә җиңел төшерелми. Ул юл авыр, әмма бик кызык. Анда янасың да, сүнәсең дә. Режиссер эшенең бөтен кызыгы шунда инде. Бу юлда гел эзләнергә, укырга, көч тупларга, рухи яктан үсәргә кирәк. Үз-үзең белән диалогка әзер булмаганда, фильмнарың сай, авырлыгы коточкыч булачак. Минем өчен фильм – энергия җыелмасы. Аңа шушы җаваплылыкны аңлаганнан соң гына алынырга кирәк. Аның бюджеты да синең әзерлегеңә бәйле. 40 яшьтә ниндидер фильм төшереп, аның башка фильмнар төшерергә, яшәргә мөмкинлек бирүен, менә шундый әйләнеш барлыкка килүен мин бик телим.

:: Нәрсәдән куркасың?

– Аллаһы Тәгалә генә куркыта ала. Башка андый көч юк.

:: Казанны нинди шәһәргә (илгә) алмаштырыр идең?

– Алмаштырырга туры килсә дә, ул вакытлыча булыр иде. Хәзер миңа – 34 яшь һәм минем Казаннан каядыр китеп торырга берниндиҗ теләгем юк. Дөрес, белем, тәҗрибә туплау өчен 1–2 елга каядыр сәяхәт итеп кайтырга мөмкин. Һиндстан, Һималай кебек көч җыю урыннарына барсаң, яки Америка кебек зур индустрия илендә андагы тәҗрибәне өйрәнеп кайтсаң, шәп булыр иде. Тормыш тәҗрибәсе туплау безнең профессия өчен бик мөһим ул. Әмма төп йортым Казан булып калыр, Алла боерса.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ЛАНДЫШ ӘБҮДӘРОВА

УМАРТА

(ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕК)

< Дәвамы. Башы 14 октябрь санында

Балны мичкәдән чүмечләп кенә чөмерделәр. Эчкәч, зиһеннәре июль челләсендәге кебек рәшәле булып кала, тик менә буыннар йомшара, аяклар йөрмәскә әйләнә. Гомерләрендә бал татып карамаганнары гәрәбә кебек балдан авыз итүгә үк сузылып төште. Тәҗрибәлерәкләренең бер ихатадан икенчесенә кадәр барып җитәрлек хәле булса да, аларын да күршедә шундый ук сары сыеклык көтә иде. «Кулак түгел, сихерче сез! Сөрәсе түгел, яндырырга кирәк сезне!» – дип җикеренде үзләре. Бу хәл күпме дәвам иткән булыр иде, анысын Каракүл халкы үзе дә белми.

Алар инде бу әрәмтамаклардан туя башлаган иде, ярдәмгә кортлар килде. Булачак коммунист Зәкиләрнең капкасына кагылганнар гына иде. Бу вакытта аларның берьюлы биш умартасы аерып ята. Зәкинең атасы Баязит абзый әле бер, әле икенче күч артыннан ак яулык тотып, ихатасы буйлап чабып йөри иде. Ак яулыкны күрүгә, чекистларның авызлары ерылды: менә бер кулак таптык, үзе бирелә, дип сөенделәр. Ул арада Баязитның ак яулыгына исе китмәгән кортларның биш күче дә берьюлы һавага күтәрелде дә берара болыт кебек куерып торгач, корт яңгыры булып, ишегалдында авызларын чөйгә элеп торган чекистларга килеп сарылды. Шешенеп беткән чекистларны Баязит абзый үзе илтеп тапшырды районга. Шуннан коммунист булып кайтты. Тышкы дөнья белән элемтәне күбрәк шул Баязит абзый алып бара иде, шуңа да «коммунист» сүзе бик килеште аңарга. Кушамат-вазыйфа мирас булып улына да калды. Авыл халкы ул вакытта күмәк хуҗалыкны үзләренчә аңлап, без болай да күмәк бит инде, дип, «Каракүл» дигән исем бирде, бал кортлары да күмәкләп йөрсен дип, авыл тирәсендәге басу-кырларга карабодай чәчте. Карабодай игү буенча Каракүл беренчелекне бирмәде.

– Бу борынгылар әйтә торган кырпы балыгына охшаган. Ите бик тәмле, диләр. Патшалар ризыгыдыр, имеш... – Миңнегали карт учын учка уа-уа шатлана. Һәрхәлдә, бу хикмәтле хәлне яхшы фал дип кабул итә: коммунист Зәки килсә дә, Ләйлинур остабикә төшсә дә, аларның фатихасын вә дә рөхсәтен алып, тизрәк эш итәргә кирәк дип уйлый иде. Шуңа да балыкны аркылыга-буйга адымлап та, карышлап та үлчәп чыкты.

– 19 карыш! – дип кычкырды ул, халыкка карап. – 19 карыш!

Ул арада Миңнегали карт тагын уяулык күрсәтеп өлгерде. Балыкны фотога төшереп калырга дигән уй иң беренче аның башына килде. Авылда фотоаппаратлы бер генә кеше бар. Зарифәнең энесе исәр Зиннур мәктәп тәмамлаганнан соң шәһәргә чыгып китеп, берничә ел югалып торган иде. Көннәрдән бер көнне аны Каракүл халкы телевизордан күреп танып калды. Кәчтүм-галстук киеп, фотоаппарат тотып, ниндидер бер партия җыелышында утыра иде. Шуннан соң озак та тормады, шул ук кәчтүм-чалбарыннан, бер иңенә фотоаппарат, икенчесенә транзистор асып, кул очына чемодан тотып, Каракүлгә кайтып төште. Башта русча гына сөйләшеп маташты. Татарчасына төрек, гарәп, фарсы сүзләре кыстыргалап кыланды. Миңнегали карт Беренче бөтендөнья сугышын да күргән кеше буларак, Зиннурны шпион түгелме икән дип шикләнде. «Ышпиун ул, андыйларны исеннән таныйм мин!» – дип, үзенекен тукыды. Икенче берәүләр: «Кем аңа ышпиунлыкны ышанып тапшырсын, галим-голәмә булып йөргәндер, артык күп укып исәрләнгән генә ул, шуңа кайтарып җибәргәннәр», – дип ышандырырга тырышты. Әмма үзенә ләм-мим берәү дә дәшмәде, төпченеп сорамады. Көне җиткәч, үзе сөйләр дип көттеләр. Зиннур кайда нишләп йөргәнен өйдәгеләренә дә әйтеп тормады, фотоаппараты белән уйнап тик йөрде. Моңа кадәр сугышлы, куышлы, качышлы уйнап юанган бала-чага өчен бәйрәм булды аның кайтуы. Зиннур урамга чыгуга, янына шунда ук бала-чага җыела. Кайткан көннән алып, Каракүл малайларын алай итеп тә, болай итеп тә төшерде фотога. Соңыннан билгеле булды: ул фотоаппаратның пленкасы юк икән... Шуннан инде Зиннурга исәр кушаматы бөтенләйгә тагылып калды. Ә фотоаппараты чыннан да әйбәт иде аның, тугыз-унда укый торган малайлар кирәк вакытта пленка алып кайтып, фото төшерергә, ясарга өйрәнде. Шулай итеп, Каракүлнең фотохроникасы барлыкка килде. Өлкәннәргә дә тиде Зиннурның файдасы. Исәр кушаматына рәнҗеп-нитеп йөрмәде, агай-энеләрне транзистор тыңларга үз тирәсенә җыя башлады. Капка төбендәге шомарып беткән имән бүкәненә чыгып утырып, радиоалгычын «Голос Америки» дулкынына көйли дә иелә төшеп тыңлый. Баштарак авылдашларын Зиннурны урап узарга котыртып йөргән Миңнегали картның үзенең кызыксынуы көчлерәк булып чыкты. Күп тә үтмәде, шик-шөбһәләрен җиңеп, «ышпиун» авылдашы янына килеп утырды да фронттан ук трофей итеп алып кайткан төрепкәсенә тәмәке тутырып, сүзсез генә тарта башлады.

– Дөньяда ниләр бар? – диде ул, өч тапкыр ашыкмыйча гына төтен суыргач, сәлам урынына.

– Салкын сугыш, – диде Зиннур да, өзелгән әңгәмәне дәвам иткәндәй.

– Сугышның салкыны да, кайнары да безнең файдага түгел, коткы таратасың, сүндер бу нәмәкәеңне. Тынычлыкның кадерен белеп кенә яшәсе, – дип, киңәшен биргәндәй итте Миңнегали карт. Ул үзе тыныч тормышның кадерен кеше сөйләгәннән генә түгел, ә сугышта үлем белән күзгә-күз очрашып йөргән кеше буларак белә иде. Зиннур каршы дәшмәде, сүндермәде дә. Берничә көннән Каракүл ирләре кич саен транзистор тыңларга йөри башлады.

Каракүлгә бәхет ишелеп төшкән көнне фотоаппарат Мостафа малаенда иде. Зарифә, тиз генә айгырына атланып, аны кайтып алды. Фотога төшәргә халык бик күп җыелган иде, бала-чага белуганың алдына, олыраклар артына басып төштеләр. Зарифә ат өстендә, Мостафа балтасын кысып кочаклаган килеш. Җиде яшьлек Камилне әнисе кочтырып төшкән кебек хәтердә калган. Фотоны хәтта газеталарда бастырып чыгардылар. Камилләрдә аның төп нөсхәсе саклана иде. Камил аны шәһәргә китеп яши башлагач, яңарттырып та карады.

«Монда мин дә бар», – дип, ядкарь итеп сакламакчы, гаилә корып, балалары, оныклары туа калса, аларга төртеп күрсәтеп сөйләмәкче иде. Ләкин ни гаҗәп: фотода үзен таба алмады. Әнисе бар, әмма ул үзе генә, гамьсез елмаеп, тик басып тора.

Ул көнне Каракүлдә балыктан кала тагын ике вакыйга булды. Еллар буе үлә алмый азапланган Самат корткасы дөнья белән алыш-бирешен өзде. Хорафатларга төрлечә карый торган Каракүл халкы, бу өч вакыйганы бергә бәйләп карыргамы, әллә болар барысы да очраклы гына туры килгәнме, дип баш ватып тормады. Самат корткасы дигәннән, аңа ничә яшь икәнне берәү дә төгәл генә белми иде. Метрикә кенәгәсенең әүвәлгесе югалган, яңасына күчереп язмаганнар. Исеме дә онытылган, хәтта бала-чаганың теленә дә Самат корткасы булып кереп калган, чөнки аның үзенә турыдан-туры дәшкән кешеләр торган саен сирәгәя бара, алары да исем белән сөйләшеп тормый. Колагы ишетми башлагач, дәшүнең кирәге дә калмады.

Соңгы елларда ул болай да урамда сирәк күренә иде. Яз җиткәндә, урамга чыгып, быел да кышны исән чыгуы өчен кешеләрдән гафу сорап утыра. Эчендә бер генә мәкере булмаса да, йөз-кыяфәте белән, озын-озак еллар халыктан аерым, мөртәт булып яшәве белән Каракүл кешеләренә ул чын Убырлы булып күренә башлаган иде инде. Авыл башындагы иске өе дә хуҗасы кебек кыегаердай нәрсәсе бар, шуның белән җиргә бөкрәеп төшкән. Анда кайчандыр – бик күптәннән, һәм аларны хәтерләүче кешеләр дә берән-сәрән генә калып, алар да хәтерләрен җуеп бара инде – хәлле кешеләр яшәгәнлеге турында морҗа турысына кадакланган тимердән чүкеп ясалган әтәч сыны – флюгер гына искәртеп тора иде.

Соңгы дистә елларда ялгыз карчыкның хәлен белергә авылның иң карт әбиләре кереп йөри иде. Бигрәк тә киленнәр курка Самат корткасыннан. Хорафатларга әвәсрәкләре аның чыннан да үлемсез булуына ышана иде. «Борын заманнарда да үлемсез кешеләр булган, диләр», – дип үзара сөйләште алар.

– Үлемсезләр матур килеш кала. Вампирлар. Мәңге ямьсез булып яшәүнең ни мәгънәсе бар?

– Алай димә, Убырлы да кан эчеп яши, ди, яшь кызларны ярата, ди, имеш. Башта чәчен тарарга куша икән. Чәч төбе тулы алтын-көмеш, ди. Ул арада алдына ятып, ботыннан канын суыра, ди...

– Болай гына Убырлы булып күренә ул кешеләргә, кирәк вакытта күз явын алырлык кызга әверелә ала, ди, имеш...

Мондый сөйләшүләрдән соң, киленнәр пешергән ризыкларын да аңа каенаналары аша биреп кертә иде. Имансыз Хәләф көлә тегеләрдән: «Галимнәр үлемсезлек генын кайчаннан бирле эзли, Самат корткасыннан гына сорыйсы бар икән!» – дип төрттерә. Әлеге борынгы карчык турында тагын бер риваять яши иде авылда: имештер, яшь чагында ул бик чибәр булган... Әлбәттә, монысына ышанучылар тагын да азрак иде Каракүлдә.

Самат корткасын җирләгән көнне Габитны авылга мулла итеп билгеләп куйдылар. «Тавышың матур, хәтерең дә яхшы, дин сабакларын бездән күбрәк беләсең, син укы», – диделәр. Мәрхүмәне гүргә иңдергәндә, Габит мулла Ләйлинур остабикә өйрәткәнчә эшләде.

Шул ук көнне өченче вакыйга булды – Мостафаның төпчек кызы туды. Аның да тәпиен юасы бар иде. Халык нишләргә белмичә, аптырашта калды: нишләсәң дә, мәрхүмә теге дөньяга киткәнгә кайгырмаган, бәби туганга шатланмаган кебек килеп чыга бит.

Дәвамы бар >

Шигърият

Гөлүсә БАТТАЛОВА

ТАПКЫРЛАУ ҖӘДВӘЛЕ

Ике икең – дүрт. Дүрт икең – сигез.
Корасы иде үзеңне шулай.
Төп-төгәл. Ачык. Артык хисләрсез.
Син – җайлы кеше. Заманга кулай.

Кемне борчый соң синең дөньяңда
Ике икең биш булган чишелеш?!
Дөрес адәмнәр төзәтер җайлап:
Кагыйдә, канун, тәртип бар, имеш!

Беркем ышанмас, синең илеңдә
Елгалар акса үрләргә табан.
Алай булалмый! Ике икең – дүрт! –
Диеп тукырлар җаныңа һаман.

Куып кертергә бердәм кысага
Тиеш! Ярамый! Яхшы түгел лә!
Һәм аның саен минем Күкләрем
Офык артына ташып түгелә!

Ике икең – биш! Кояшым яшел!
Чирәмем зәңгәр, чиксез галәмем!..
Кисәткән идек, дияр күргәннәр
Җирдән сөрүен мине гавамнең.

Качып бетәрләр дөрес иптәшләр,
Ваз кичәр, бәлкем, бүгенге дус-иш.
Үзгәрер гәүдә. Үзгәрмәс иман.
Бигайбә, дөнья, ике икең – биш!

ҖИТӘР ВАКЫТ

Җитәр вакыт: яшәү башка булыр,
Караңгыны куар яктылык.
Ни булса да булсын, дөньясыннан
Югалмасын гына яхшылык.

Җитәр вакыт: яратулар аша
Без менәрбез тормыш үренә.
Җитәр вакыт, давыллардан куркып,
Бер адым да артка чигенмә.

Җитәр вакыт: безнең уллар инде
Бөркет булып очар оядан.
Ул чакта да нәкъ бүгенге кебек
Бу дөньяны сөеп туялмам.

Җитәр вакыт: ерагаер бездән
Бу елларның салкын сөреме.
Үз юлымнан алга таба атлыйм
Җилгә каршы куеп йөземне.

ЯБЫК ПӘРДӘ. БИКЛЕ ИШЕК

Куш йодрыкка төйнәлдем дә...
тынып калдым.
Рәхәт икән... Ябык пәрдә. Бикле ишек.
Җиде ятып, бер төшемә кермәс төсле
Кайда кырау, кайда чиллә, кайда җепшек.

Рәхәт икән – йонга төреп йөрәк итен,
Кыштыр-мыштыр җан асравың
йорт-кураңда.
Барыбер күк нинди сурәт, яисә тамга
Борынгыдан күтәрелгән җан туграңда.

Булды инде, булды юкса афәтләрдән
Бер йөрәктә талкынуы мең халәтнең!
Күкләр биргән соңгы җәзамы соң
Үз-үзенә кул салуы мәхәббәтнең?!

Упкын чиге убылганда исән калып,
Үзең булып кала алу җиңел әллә?
Котылуың сөенече кемгә хаҗәт
Дөнья чоңгыл авызына чумган мәлдә?

Куш йодрыкка төйнәлдем дә тынып калдым...
Утсыз төтен җанны буа туңып-өшеп.
Рәхәт түгел... Кычкырамын... Ишетмиләр...
Ишетмиләр... Ябык пәрдә. Бикле ишек...

ЧИРАТ ТОРУЧЫЛАРГА 10 КИҢӘШ

1 Дәүләт оешмасына барырга җыенсагыз, Gosuslugi.ru яки Uslugi.tatarstan.ru порталларына кереп карагыз, бәлки, кирәкле эшне шуннан башкарып буладыр. Монда кирәкле бланкларны табарга, пошлина түләргә дә мөмкин.

2 Кәгазьләрегезне алдан әзерләп куегыз. Кирәк булмас дигән документларны да алыгыз. Еш кына алар да кирәк булып куялар.

3 Запаска чиста кәгазь битләре алыгыз. Кыстыргычлы катыргы планшет та яхшы. Гадәттә, бланк тутыру өстәле буш булмый.

4 Ике каләм алып барыгыз. «Кайчан язып бетерә инде бу, ручкасын сорап торыр идем», – дип өстегездә тормаслар.

5 Аерым папкада бөтен документның күчермәсе булу комачауламас.

6 Иң элек чират алыгыз. Шуннан соң кайда һәм нишлисен сорашыгыз. Бәлки, башны тыгып бланк аласыдыр, бүтән кабинетка керәсеңдер, диварда гариза язу үрнәге бардыр.

7 Бланк алганда «мин язганда гел ялгышам» дип, икене сорагыз. Әбит, һичшиксез, ялгышачаксыз.

8 Кайбер җирдә кызлар бланкны 100–200 сумга тутырып бирә.

9 Балагыз яки лаеклы ялдагы әти-әниегезне дә иярткергә була. Берничә кабинетка керәсе булса, яки документ тутырганда чират сакларлар.

10 Бу көнне кичкә бәйрәм-фәлән планлаштырмагыз. Беренчедән, озын чират торып, бланкларны яңадан күчереп язып, урындагы кешеләрнең уфылдаганын тыңлап, кәефегез тәмам кырылган булыр. Икенчедән, мондый оешмада эшең бету – үзе бәйрәм!

Әз-мәз мәзәк

* * *

– Алло, син кайда?

– Гер күтәрүчеләр ярышын карап утырам.

– Бүген кемнәр ярыша: ирләрме, хатын-кызлармы?

– Әле аңламадым.

* * *

– Сездә сатуда киләсе ел календаре бармы?

– Оптимист икәнсең.

* * *

– Доктор, сезгә пациентларыгыз бүләкләр белән киләме?

– Мин – патологоанатом.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: канәгатьсезлек, ислам, ал, Елмай, анод, Круз, Нәби, йон, гаилә, ис, ым, журнал, Бари, Күктау, Ирнис, ромб, ураза, рам, жәл, Леонтьев, Алла, ыру, Ык, ял, Ом, Ермак, мишәр, бума, Рахманкул, карачкы.

Вертикаль: кыстыбый, карлыгачлар, аек, анык, Мо, МТЗ, Аты, дежур, Таишев, егерме, Кәримов, бу, салам, Ямаш, ул, Алабуга, бала, Зум, залим, кармак, Ли, нужа, Нәбирә, асалы, бир, ро, Әбугалисина, умартачы.



Разый булмау; К. Насыйри хикәясе; Мәсәлманнар дине; Үсемлекле түбә; Кызгылт төс; Онлайн-элемтә программасы; Биектау мае; «Санта-Барбара»-дан ... Кастильо; Явыз, изүче; Ачык, аңлаешлы; Катод һәм...; Күренекле татар шагыйре ...Дәүли; Сарык ул ит кенә түгел; Ишарә; «Чаян», «Сәмбикә»; Әти, әни һәм мин; Борын «азыгы»; Казанда татар кафесы; «...оя ясый»; Минск тракторы; Мохтаҗлык; Шагыйрь ... Рәхмәт; Илдар Ягъфәров фильмы; Шишкин каласы; Дирижёр ... Рахимуллин; Боерып сорау; Исерек түгел; Франция өлкәсе; Геометрик фигура; Күңеле далада; Ислам баганасы; Тәрәзәдә пластик; Кизү; «... миллион» җыры; Иманы Камил; «Алым түгел, гөлем түгел, Җаным ... түгел синә»; Грек хәрефе; Бал-бабай; Җырчы Валерий ...; Нәсел; Татарстанда елга; Арчада Субаш ... авылы; Танылган казах атаманы; Балык Бистәсе районы авылы; Эш беткәч, уйнарга ярый; ... Пугачева; Җеп кыстырылган; Физик Георг Симон ...; Татарның каймагы; Балыкчы кулында; Мин, син, ..., алар; «Ах син, Дума, Дума, Дума, эшләгән эшең ... ?»; Самавыр пары; Бакча сакчысы

Беләсең килсә...

1 **«Зинһар өчен кермә төшләремә» җырының көен кем язган?**
а) Луиза Батыр-Болгари;
б) Сара Садыйкова;
в) Резеда Әхиярова.

2 **Беринг бугазы – Азия һәм Төньяк Америка арасында. Аны ачкан сәяхәтче Берингның исемен хәтерлисеңме?**
а) Вильгельм;
б) Витус;
в) Витас.

3 **Геологка һәйкәл Татарстанның кайсы шәһәрендә урнашкан?**
а) Бөгелмә;
б) Әлмәт;
в) Лениногорск.

4 **Бер гигабайтта ничә мегабайт?**
а) 100;
б) 1000;
в) 1024.

Җаваплар: 1.в); 2.б); 3.а); 4.б).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15318 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 355

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+